## ТАТАРСТАН КОНСТИТУЦИЯСЕ

**Дәүләт Советы Рәисе белән республиканың Төп Законы турында әңгәмә**

> 4–5

## БӘРӘКӘТЕ БУЛСЫН!

**Авылларда өмә, сугым чоры башлана**

> 17

## РАМИЛ МИНДИЯР:

**«Җырлаганда шул җырда эреп бетмисең икән, ул тамашачыга «тими»**

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 163 (28936) | Җомга | 4 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

«Татар-информ»

# КАДЕРЛЕ КАВЕМ

## ИР-АТ АБРУЕ ХАКЫНДА УЙЛАНУЛАР

**Соңгы 20 елда Россиядә хатын-кызлар саны ир-атлар санынннан күпкә артты, ди статистика. Хәер, дәлил эзләп, ерак барасы да юк. Бу инде – күрер күзгә сизелерлек чынбарлык. Яклаучы һәм саклаучы, үрнәк һәм дәрәҗәле, әйтер сүзе, кылган гамәле булган ир-атлар, чынлап та, азмы икән? Әллә бар гаеп ирне ир дә, хур да иткән гүзәл затлардамы? Ноябрь – ир-атлар турында күбрәк уйланырга мәҗбүр итә торган ай. Ник дигәндә, бу айда Халыкара ирләр көне билгеләп үтелә. Төрле җирләрдә төрле көннәрдә булса да, асылы бер аның: ир-ат та кадерләүгә, игътибарга һәм яклауга мохтаҗ.**

> 7

# ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ КӨНЕ БЕЛӘН!



**Халыклар бердәмлеге көне уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ МӨРӘҖӘГАТЕ**

Хөрмәтле татарстанлылар! Кадерле ватандашлар!

Сезне татулык, дуслык һәм күпмилләтле Россиянең куәте күрсәткече булган бәйрәм – Халыклар бердәмлеге көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәм!

Күп гасырлар элек ата-бабаларыбыз – төрле катлау, дин һәм милләт вәкилләре – Ватанның бәйсезлегенә, бүленмәслегенә куркыныч янау шартларында бер булып баскыннарны илдән куып чыгаруга һәм болгавырлыкны җиңүгә иреште. Туган җирне ярату, каһарманлык, оешканлык, үз-үзеңне аямау, азатлыкка һәм гаделлеккә омтылу – чын кеше һәм гражданга хас булган әлеге асыл сыйфатлар халкыбызга дәүләтебезне саклап калырга һәм җиңү яуларга ярдәм итте.

Ватаныбызга чит илләрдән моңарчы күрелмәгән көчле басым ясалган һәм ачыктан-ачык катгый каршылык барышында аның ныклыгы сыналган хәзерге көндә дә бу сыйфатлар гаять зур әһәмияткә ия. Ата-бабаларыбызның данлыклы гамәлләре, бердәмлегебез, Россия халкының нык ихтыяры, максатчанлыгы һәм чыдамлыгы хәзерге чорның теләсә нинди авырлыкларын җиңүгә омтылышыбызны көчәйтә.

Болганчык чорда фетнәгә каршы көрәшү өчен Минин һәм Пожарский җитәкчелегендәге халык гаскәре сафына батыр улларын бастырган борынгы җиребез – Татарстан бүген дә Россия дәүләтчелеге иминлеген саклауда таяныч үзәкләренең берсе, төрле милләт һәм дин вәкилләренең үзара тату һәм килешеп яшәвенең гүзәл үрнәге булып тора. Мәскәүне чит ил яулап алучыларыннан азат итүнең төп рухи символы буларак нәкъ менә Казан Мәрьям Ана иконасының танылуы шул хакта сөйли. Изге хакыйкатьне без гасырлар аша йөрәкләребездә саклап килдек һәм явызлыкка каршы булган һәркемне Ватаныбызга, ата-бабалардан мирас булып калган телебезгә, мәдәниятебезгә һәм гореф-гадәтләребезгә тугры булырга өндибез.

Илебез халыкларының һәм этник берлекләренең милли үзенчәлекләрен саклау мәсьәләләренә зур игътибар бирелгән Россия халыкларының мәдәни мирасы елында Халыклар бердәмлеге көненең әһәмияте аеруча арта. 2023 елда Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елында да шундый ук бурычлар һәм максатлар куела.

Россия халкының һәм ул төзегән бөек дәүләтнең бөтенлеген милли һәм дини күптөрлелекне, мәдәни асылыбызны ныгыту аша гына саклап калырга мөмкин.

Халыклар бердәмлеге көнен бәйрәм итү гражданлык һәм ватанпәрвәрлек хисләрен үстерүгә, күпмилләтле халкыбызның тагын да берләшүенә күркәм этәргеч бирәчәк, Ватанга мәхәббәтебезне һәм үз көчебезгә ышанычыбызны тагын да арттырачак дип ышанам.

Һәркемгә исәнлек-саулык, бәхет һәм иминлек телим!

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ КӨНЕ БЕЛӘН!

**Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВның Татарстан Республикасы Конституциясе көне уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ**

Хөрмәтле татарстанлылар! Сезне Татарстан Республикасы Конституциясе көне уңаеннан тәбрик итәм.

1992 елның 6 ноябрендә Төп Закон кабул ителү нәтиҗәсендә республиканың сәяси корылышына һәм социаль-икътисадый үсешенә нигез салынды, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының үзара килешенгән эшчәнлеге тәэмин ителде.

Борылыш чорында Татарстан Конституциясе, республикаың күпмиләтле халкы ихтыярының ачык чагылышы буларак, гражданнарның ирекен һәм киң хокукларын гарантияләде, иҗтимагый үсешкә, милләтара һәм динара татулыкка, җәмгыятьтә тынычлык урнашуга ныклы таяныч булды.

Үткән өч дистә елдагы вакыйгалар республикада яшәүче барлык халыкларның тарихи, милли һәм рухи хәзинәләрен, мәдәниятен һәм телен саклауда һәм үстерүдә Төп Законның зур әһәмияткә ия булуын дәлилли.

Бүген Татарстан ышанычлы адымнар белән алга бара һәм, илнең тәрәк тәбәкләреннән берсе буларак, Россия Федерациясе дәүләтчелеген, аның көчен, оборона куәтен ныгытуга мөһим өлеш кертә.

Зур тизлектәге үсешебез кешеләрнең тормыш шартларын яхшыртырга, шәһәрләрдә һәм авылларда көнкүреш өчен уңайлы даирә булдырырга, торак төзергә, сәнәгатьне, медицина, мәгариф һәм фән өлкәләрен үстерергә, талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтергә, социаль йөкләмәләребезне үтәргә мөмкинлек бирә. Төп Законның фундаменталь нормаларына һәм нигезләмәләренә таянып, республика хакимиятенең барлык органнары кешеләр турында кайгырту бурычын иң беренче урынга куя.

Бездә ватанпәрвәрлек хисләре тәрбияли торган Татарстан Конституциясенең берләштерү роле читтән көчле басым ясалган хәзерге шартларда тагын да арта. Илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путин тирәсендә тупланып, без илебез бердәмлеген ныгыту эшен дәвам иттербез һәм кыенлыкларны бергәләп җиңеп чыгарбыз дип ышанам.

Хөрмәтле татарстанлылар! Кадерле ватандашлар!

Сезгә нык сәламәтлек, хезмәтегездә уңышлар, бәхет һәм иминлек телим!

### ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

# УРТАК ТЕЛ ХАКЫНА

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Бәхрәйн дәүләтенә эш сәфәре кылды. Форумда чыгыш ясау, уртак хезмәттәшлек мөмкинлекләрен барлау – эшлекле очрашулар нинди нәтиҗәләр бирер?

Республика Президенты «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау рәисе буларак «Диннәр арасында диалог әһәмияте» форумында чыгыш ясады. Сүз уңаеннан, быел әлеге форумның темасы Көнчыгыш һәм Көнбатыш мөнәсәбәтләренә багышланган иде. Әлеге чарада 200ләп дин әһеле, галимнәр һәм рәсми затлар катнашты.

Чарада катнашучыларны сәламләп, Рөстәм Миңнеханов мондый мәйданчыкларның фикер алышу һәм сорауларга җавап табу өчен әһәмиятле булуын әйтте.

– Төрле халыкларның һәм диннәрнең тату яшәве һәм үзара хезмәттәшлеге юнәлешендә Татарстан үрнәк булып тора, – диде Татарстан Президенты. – Ислам – Россия цивилизациясенең аерылгысыз өлеше. Бу хакта Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүнең федераль дәрәҗәдә узуы да сөйли. Әлеге карарны Россия Президенты Владимир Путин кабул итте.

Татарстан Президенты катнашучыларга республиканың дин һәм милләтара татулыкны саклау юнәлешендә башкарган эше турында сөйләде. Ул искәрткәнчә, Татарстанда 170тән артык милләт вәкиле яши.

Моннан тыш, форум кысасында Татарстан Президенты Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы Генераль секретаре Хөсәен Ибраһим Таха белән очрашты. Рөстәм Миңнеханов оешма җитәкчелегенә һәрьяклы ярдәмнәре өчен рәхмәт белдерде һәм аны Казанга килергә һәм KazanSummit чараларында катнашырга чакырды.

***

Рөстәм Миңнеханов Бәхрәйн Премьер-министры, варис принц Сәлмән бән Хәмәд бән Гайса Әл Хәлифә белән очрашты. Ике арадагы сөйләшү ике як өчен дә файдалы булган үсеш юнәлешләрен барлауга багышланган иде. «Бер-беребезне яхшырак аңларга һәм мөселман илләре белән бизнес алып барырга безгә уртак дин, тарихи һәм мәдәни традицияләр ярдәм итә. Без ислам дөньясы белән актив хезмәттәшлек итәбез», – диде Татарстан Президенты.

***

Татарстан Президенты Бәхрәйннең Ислам эшләре буенча югары совет рәисе шәех Габдеррахман бән Мөхәммәд бән Рәшит Әл Хәлифә белән очрашты. Президент искәрткәнчә, Россия Бәхрәйн белән мөнәсәбәтләрне ныгыту зур әһәмият бирә, бу эшкә Татарстан да үз өлешен кертә. Рөстәм Миңнеханов Бәхрәйн компанияләрен Татарстанда инвестиция проектларында катнашырга чакырды.

Каршы якның да хезмәттәшлек итү теләге бар. «Россиядә мөселман кардәшләребезгә булган мөнәсәбәт өчен дә рәхмәт белдерәсебез килә», – диде шәех.

# ТУГАН ЯКТАН КҮЧТӘНӘЧ

## КАЗАНДА ИКЕНЧЕ ГУМАНИТАР ЯРДӘМ СКЛАДЫ АЧЫЛДЫ

**Ярдәм янәшә!**

**300 тартма, 2 тонна йөк. Апас районыннан Казанга әнә шулкадәр күчтәнәч алып килделәр. Ватан алдында бурычын үтәргә киткән егетләргә ярдәм йөзеннән җыелган гуманитар йөкне саклау өчен, башкаланың Киров районында икенче склад ачылды. Беренчесе тулган инде.**

Әле бу көннәрдә генә эшли башлады ул. Атна башыннан бирле бирегә Чаллыдан, Менделеевск, Буа, Лаеш районнарыннан, башкала читендәге Усад бистәсеннән гуманитар йөк китерергә өлгергәннәр инде. Зур ярдәмнең чираттагысы Апас районыннан килде. Бу районадагы «Яшьлек» яшьләр үзәге җитәкчесе Илдар Салаватов сүзләренә караганда, районнан җибәрелгән икенче гуманитар ярдәм бу. Аңа кадәр Татарстан шефлыкка алган Лисичанск шәһәренә 20 тонна гуманитар йөк җибәрелгән булган алар.

– Бу эш алга таба да тукталмаячак. Район халкы бу изге эшкә кулыннан килгән кадәр үз өлешен кертте. Бүген бирегә 2 тонна чамасы йөк китердек. Тартмаларга шәхси гигиена әйберләре, азык-төлек, дарулар тутырылган, – ди Илдар Салаватов.

«Ярдәм янәшә!» хәрәкәте координаторы Тимур Сафин сүзләренә караганда, районнан килгән гуманитар ярдәм җентекләп тикшерелә. Тартмаларны бушатып, анда салынган әйберләрне барлап, озатырга әзерлиләр.

– Йон оекбаш белән кайнатма бер тартмада саклана алмый бит инде. Шуңа күрә складка килгән гуманитар ярдәмне яңадан «сүтеп җыябыз». Республика халкы бу эшкә бик җаваплы карый. Фронтка атап җыелган ярдәм әле дә килә тора. Гуманитар ярдәм шулкадәр күп, хәтта аларны бер складка гына сыйдырып бетереп булмый башлады. Шуңа күрә икенчесен ачарга туры килде. 1000 кв. метр мәйданлы шундый иркен, чиста яңа складыбыз бар хәзер, – ди Тимур Сафин.

Татарстанда барлыгы 60 гуманитар ярдәм кабул итү пункты бар. Шуларның 18е – Казанда. Аннары аларны ике зур складка җыялар. Склад хезмәткәрләренә волонтерлар ярдәм итә. Районнардан килгән гуманитар ярдәмне бушату, санаудан алып, олы юлга озатырга әзерләү кебек эшләрнең барысында да катнаша алар. «Пандемия вакытында ярдәмнең никадәр мөһим икәнлегенә бер инанган идек инде. Бүген менә шушындый каталаулы чорда да солдатларыбызга аз гына булса да ярдәм итә алуыбызга шатбыз. Тартмаларга әйберләрне илләребез тыныч булсын, егетләребез исән-сау әйләнеп кайтсын дигән изге теләк белән тутырабыз», – ди «Волонтер медиклар» хәрәкәте активисты Әдилә Нәбиуллина.

Ил-көнгә зур сынау килгән көннәрдә ярдәмнең артыгы юк. «Бик күп кеше, берләшмә, оешмаларның көче кергән зур эш бу. Гуманитар ярдәм җыю эшенә өлеше кергән һәркемгә зур рәхмәт. Мондый чакта бердәм булсаң гына тормыш бара», – ди Тимур Сафин.

Яңа гуманитар ярдәм складына җыелган йөк 9 ноябрь көнне Лисичанск шәһәренә озатылачак. Тагын ике атнадан зур гуманитар ярдәм колоннасы юлга кузгалачак.

Исегезгә төшерәбез: өлешчә мобилизация башланугa, республикада «Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәте волонтерлары яңадан эшкә керәште. Хәтерләсәгез, ике ел элек тормышыбызга «коронавирус» дигән зәхмәт үтеп кергәч тә, әлеге хәрәкәт волонтерлары иң беренчеләрдән булып ярдәмгә ашыкты. Хәзер алар мобилизацияләнгән егетләргә кирәк-яраклар җыю, аларның гаиләләренә булышу, бушлай юридик ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

✓ «Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәте оештырган гуманитар ярдәм җыю пунктларының адресы һәм эш графигы белән «ярдәм.рф» сайтында танышырга мөмкин.
✓ Волонтерлар ярдәменә мохтаҗ кешеләр 8(800) 350-02-16 номеры буенча мөрәҗәгать итә ала. «Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенә кушылырга теләгән кешеләргә дә шушы номер буенча шалтыратырга кирәк. Шалтыратулар иртәнге сәгать тугыздан кичке алтыга кадәр кабул ителә.

**Шулай ук әлеге QR-код белән матди ярдәм күрсәтергә мөмкин.**

# ДУСЛЫК ЮЛЫ

**Нәтиҗәләр ясар чак җитте. Казанда Татарстан халыклары ассамблеясының 30 еллыгын билгеләп уздылар. Әлеге оешма советы утырышының Халыклар бердәмлеге көне алдыннан узуы үзе үк аерым мәгънәгә ия. Бәйрәм белән котлашкан арада, бүген бу дуслыкның ни дәрәҗәдә мөһим булуы турында да фикер алыштылар.**

tatarstan.ru

Утырыш юбилей кысасында узганга, аңа үзенә күрә бәйрәм рухы хас иде. Ә бәйрәм котлауларсыз булмый. Россия Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Игорь Комаровның котлау сүзләрен аның урынбасары Игорь Паньшин җиткерде. Котлауда Татарстанда төрле милләт һәм дин вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең билгеле бер системага салынуы, бу өлкәдә Халыклар ассамблеясы эшчәнлегенең өлеше зур булуы әйтелгән.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та, эш сәфәрендә булуына карамастан, утырышта катнашучыларга сәлам һәм котлау сүзләре юллаган. Аныңсын Президент Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров җиткерде. Рөстәм Миңнеханов та Халыклар ассамблеясының Россиянең Дәүләт сәясәте стратегиясен тормышка ашыруга зур өлеш кертүен, хәзерге вакытта ил кичергән авыр чорда бергә һәм бердәм булуның әһәмияте артуын билгеләп узган.

### Тарих сәхифәләре

Утырышның төп өлеше Татарстанның Халыклар ассамблеясы советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның моннан 30 ел элек булган вакыйгаларны, ул чакта җәмгыятьтә хөкем сөргән рухны искә алуыннан башланды.

– Республикада Халыклар ассамблеясы төзелүгә заман рухы, Татарстанның мөстәкыйльлеге, үз язмышы өчен җаваплылыгы, республика халкының өмете, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең зирәклеге һәм алдан күрүчәнлеге этәргеч булды. Күп төрле милләтләрнең инде күп гасырлар дәвамында Татарстан җирендә гомер кичерүе үзара аңлашып яшәүнең нигезенә әверелгән уникаль формула китереп чыгарган. Аны без «күптөрлелектәге көч» дип атыйбыз, – дип сөйләде парламент башлыгы. – Республикадагы этномәдәни хәрәкәткә 1992 елның 23 маенда узган Татарстан халыкларының беренче съезды нигез салды. Ул вакытта телләр һәм мәдәниятләр үсешенең дәүләт программасын кабул итү, республикада гамәлдә булган милли-мәдәни җәмгыятьләрнең эшчәнлеген көйләү һәм аларны берләштерү өчен Халыклар дуслыгы йорты булдыру турындагы идеяләр яңгырады. Дистәләгән еллар узганнан соң, бер шиксез әйтә алам: ул чакта алдыбызга куйган бурычларны үти алдык. Республиканың күпмилләтле халкын берләштерә алган юл табылганлыгын вакыт үзе күрсәтте.

Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, шушы 30 ел эчендә Татарстан халыклары ассамблеясы республикада яшәүче милләтләрне берләштерә торган үзәк булып торды. Бүген Ассамблея канаты астында 257 милли-мәдәни оешма бар. Республиканың шәһәр һәм районнарында 2 филиал һәм 36 вәкиллек эшләп килә. Парламент рәисе Татарстанда уздырыла торган милли бәйрәмнәргә, аларның республиканың милли-мәдәни тормышында зур роль уйнавына да тукталды. Моннан тыш, республикада туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләсенә игътибар зур булуын ассызыклады, Татарстанда күпмилләтле якшәмбе мәктәбе эшләвен билгеләп уздры. Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта әлеге мәктәптә 23 милли бүлек эшли.

– Шушы вакыт аралыгында Татарстан халыклары ассамблеясы җитди оешмага әверелде. Аның милли һәм милләтара проблемаларны хәл итүгә, телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклауга юнәлтелгән эшчәнлеге, хакимият органнары, фәнни, мәгариф һәм хокук саклау структуралары белән тыгыз хезмәттәшлектә булуы милли-мәдәни үсеш өлкәсендә күпкырлы һәм катлаулы эшне көйли, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

### Бердәмлектән башка уңыш юк

Чарада Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев тә катнашты. Ул да, Фәрит Мөхәммәтшинның сүзләрен җөпләп, республика сайлаган юлның уңышлы булуын әйтте.

– Без сезнең белән тарихи вакыйгаларның тере шаһитлары булып торабыз. Республика үткән юллар һәм еллар катлаулы булса да, алар безне яхшы якка үзгәртте. Үз кулларыбыз һәм аңыбыз белән без киләчәгебезне язабыз, үзебезне һәм әйләнә-тирәбезне үзгәртәбез. Шушы еллар дәвамында без бер-беребезгә якынайдык, бер-беребезне яхшырак аңлый башладык. Һәм бу сайлаган юлыбызның дөреслегенә тагын бер кат ышандыра, – диде ул.

Россия халыклары ассамблеясының мактаулы рәисе, Россиянең Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы каршындагы махсус вәкиле Рамазан Абдулатыйпов та тарих сәхифәләрен барлады, Татарстанның беренче Президентының республика үсеше өчен керткән бәһасез өлешенә тукталды.

– Мин бүген кабаттан Шәймиев, Миңнеханов һәм Мөхәммәтшинның тәүлегенә 24 сәгать буе халыклар дуслыгы турында уйлауларына инандым. Алар – бер үк вакытта бөтен милләт вәкилләре дә. Менә нәрсәдә ул уңышның сере! Милләте, дине буенча аермыйча бар кешегә дә кешечә карау. Без уникаль илдә яшибез. Әгәр Россиядә гомер кичерүче барлык милләт вәкилләре дә бер йодрыкка тупланып, үзләрен зур һәм бердәм халык итеп тоймаса, ил уңышка ирешә алмаячак. Кызганыч, бу өлкәдә, Татарстан тәҗрибәсеннән үрнәк алып, тиешле дәрәҗәдә эшләүчеләр җитми, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

## ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ НӘРСӘ УЛ?

**Фикрәт БАКИРОВ, Әлмәт шәһәрендә яшәүче азәрбайҗаннарның «Бирлик» оешмасы җитәкчесе:**
– Татарстан күпмилләтле республика булуы белән көчле. Дөресен генә әйткәндә, без бүген генә түгел, ел буе диярлек бәйрәм итәбез. Халыклар дуслыгын, бердәмлеген саклауга юнәлтелгән чаралар бик еш оештырыла, моңа бик зур игътибар бирелә. Миңа калса, безнең җитәкчелек бу өлкәдә бик дөрес сәясәт алып бара. Бу байлыкны саклау, чыннан да, бик мөһим бит. Киләчәктә дә бу эшне аңлап дәвам иттерергә кирәк.

**Сәэсгма БУБЕЕВА, Казан бурятларының милли-мәдәни автономиясе җитәкчесе:**
– Халыклар бердәмлеге көне – гаиләләребез, халкыбыз, илебез өчен төп бәйрәмнәрнең берсе. Ул, беренчедән, кем һәм нинди милләттән булуыңны аңларга, икенчедән, Россиянең никадәр киң, матур, кешеләре һәм мәдәнияте белән бай һәм күптөрле икәнен күрергә мөмкинлек бирә. Халыклар бер-берсе белән дус-тату, аңлашып һәм хөрмәт итешеп яшәгән ил башка бер җирдә дә юк. Иң мөһиме, алар бер-берсе белән аралашып яши.

**Асефи Мөхәммәд ШӘРИФ, «Әфганстан бердәмлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе:**
– Россиядә – 193, Татарстанда 173 милләт вәкиле яши. Бу бәйрәм илебездә яшәүче һәр кеше өчен әһәмиятле булырга тиеш. Халыклар бердәмлеге – бер илдә яшәгән барлык милләтләрнең, аларның күпме булуына карамастан, берләшеп яшәве дигән сүз. Бергә булганда, барлык авырлыкларны да җиңәсең. Халыкларның бердәм булуы бүгенге вазгыятьтә аеруча мөһим. Минем уемча, Россия җиңәр. Бу җиңүне Россия халкы гына түгел, дөньяның күпчелек илләрендә яшәүчеләр көтә, дип уйлыйм.

**Константин МАЛЫШЕВ, Татарстанның чуаш милли-мәдәни автономиясе рәисе урынбасары:**
– Әлеге бәйрәм төрле дин, тел, гореф-гадәтле милләт халыкларын берләштерә. Православие динендәгеләр буларак, без бу көнне Казан Изге Ана иконасы бәйрәмен дә билгеләп үтәчәкбез. Гадәттә, без аны рәсми чаралардан соң, гаилә, туганнар белән җыелып үткәрәбез. Шунысы игътибарга лаек: безне бу бәйрәм белән татарлар котлыйлар. Без дә татарларны мөселман бәйрәмнәре белән котлыйбыз. Без төрле, әмма без бердәм. Бәйрәм – шуның хакында.

# ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН:
# «ТӨП ЗАКОННЫҢ ҺӘРБЕР СҮЗЕ КЫЙММӘТЛЕ»

**6 ноябрьдә Татарстан Конституциясе кабул ителүгә 30 ел тула. Республика парламенты 1992 елда, Россия төбәкләре арасында беренчеләрдән булып, Татарстанның Төп Законын кабул итүне бертавыштан хуплады. Әлеге тарихи вакыйга республиканың сәяси һәм социаль-икътисади үсешендә яңа этапны башлап җибәрде. Мөһим вакыйга алдыннан Дәүләт Советы Рәисе, сәяси фәннәр докторы, җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның Төп Законын эшләү һәм кабул итүдә турыдан-туры катнашкан Фәрит МӨХӘММӘТШИН «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталары вәкилләре белән әңгәмә корды.**

### Халык фикере

**:: Фәрит Хәйруллович, республика Конституциясе кабул ителүгә утыз ел тулды. Бүгенге күзлектән караганда, әлеге вакыйгага нинди сәяси бәяләмә бирер идегез? Сезнеңчә, Төп Законыбызның тарихи әһәмияте нидә?**

– Бу җәһәттән иң элек шуны әйтергә кирәк: республика Югары Советы 1992 елда беренче тапкыр Россия һәм Татарстанның яңа тарихындагы сынау-кыенлыкларга тулысынча җавап бирердәй, республиканың күпмилләтле халкы мәнфәгатьләрен чагылдырырдай сәяси-хокукый документ кабул итте. Конституциянең төп үзенчәлеге шунда: ул тәүге тапкыр Татарстанда яшәүчеләрнең фикереннән чыгып эшләнде, төрле милләт вәкилләрен, төрле сәяси карашлы һәм төрле дин кешеләрен берләштерә алды... Әлеге берләшүнең нигезендә яңа дәүләтчелек булдыру, социаль һәм икътисади бурычларны хәл итүдә республиканың мөстәкыйльлеген үстерү, Татарстанның бүгенгесе һәм киләчәген эчкерсез кайгырту, аны демократик хокукый дәүләт, гомумроссия сәяси процессларында катнашучы итү омтылышы ятты.

Шушы еллар эчендә республика һәрвакыт Россия Федерациясенең бөтенлеген һәм бердәмлеген, халыклар арасындагы дуслык һәм хезмәттәшлек традицияләрен ныгыту сәясәтен алып барды.

Тагын бер кат искә төшерик: Төп Закон бик катлаулы сәяси шартларда кабул ителде. 1992 елгы референдум Конституция кабул итүдә мөһим адымга әйләнде: анда халыкның 61,4 проценты Татарстанның мөстәкыйльлеген үстерүне хуплап тавыш бирде. Халыкның фикере Конституциянең беренче маддәсендә теркәлде.

Гомумән алганда, Татарстанда яшәүчеләр үзләре үк бүгенге Конституцияне иҗат итүчегә әйләнде. Төп документ галимнәр, сәясәтче, җәмәгать эшлеклеләренең кулы белән язылды. Конституция комиссиясе (ә аның белән Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев җитәкчелек итте) аларның барлык тәкъдимнәрен исәпкә алды. Ике ел эчендә Конституция комиссиясенә халыктан биш меңнән артыграк тәкъдим керде!

Конституция барлыгы җиде бүлектән, дүрт кисәктән һәм 126 маддәдән тора. Аның һәрбер сүзе кыйммәтле һәм аерым бер әһәмияткә ия. Төп Закон халык хакимияте, кеше хокуклары һәм ирекләренең өстенлеге, социаль гаделлек, хакимият бүленеше, дәүләт телләренең тигезлеге, җирле үзидарә органнарының мөстәкыйльлеге, икътисади эшчәнлек иреге һәм бүгенге Татарстанның сәясәтен формалаштырган башка нигезләмәләрне төп кыйммәт буларак игълан итте. Конституциянең республикадан читтә яшәүче татарларда милли мәдәниятне, телне үстерүгә, көнкүреш үзенчәлекләрен саклауга ярдәм итүне күздә тоткан маддәсе татар халкының берләшүенә дә ярдәм итте.

> Бүген Татарстан – динамикалы төстә үсүче, икътисадта, мәгариф, инновацияле җитештерү булдырыда кыю планнар белән яшәүче төбәк. Хәзерге вакытта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендә ныклы үсешкә йөз тоткан бу процессларга республика Конституциясе нигез салды. Татарстанның күпмилләтле халкы өчен, Россиянең бүгенгесе һәм киләчәге өчен аның тарихи әһәмияте нәкъ менә шунда.

**:: Кайвакыт галимнәр, тегe яки бу вакыйганың әһәмиятенә төшенү өчен, гап-гади әйберне: аның юкка чыгуын һәм нәтиҗәләрен күз алдына китерергә киңәш итә. Конституцияне тормышыбыздан алып ташлаган очракта ничегрәк яшәешебезнең буласын күзалларга мөмкинме?**

– Кызык сорау. Конституция җәмгыятьне кору һәм анда яшәү кагыйдәләрен булдыру өчен төп документ булып тора. Әйтик, йортның нигезе кебек ул. Нигезе никадәр ныграк икән, йорт шуның кадәр ышанычлырак, дигән гыйбарә бар. Кинәт кенә Конституциянең юкка чыгуын күз алдына китерәсеме? Йортның нигезен сүтсәк, нәрсә була? Конституциябездә урын алган сәяси нигезләр һәм закон нигезләре киләчәккә карап салынган. Ә инде нәрсәне төзеячәгебез безнең үзебезгә бәйле.

### Үзәктән бер елга алдан

**:: Татарстан Республикасы Конституциясе федераль үзәкнекеннән бер елга алданрак кабул ителде. Аларның үзара мөнәсәбәтләре тарихы нинди? Бер-берсенә комачауламыйлармы? Ни өчен шул чагында республика тагын бер ел көтмәгән?**

– Республика Конституциясенең федераль Конституциядән бер елга алданрак кабул ителүе, һичшиксез, вакыт таләбе инде. СССР таркалу һәм идеология алышыну илдә зур сәяси һәм икътисади кризиска китерде. Нәкъ менә шул чагында җәмгыятьнең сәясәтен реформалау мәсьәләсе күтәрелде, хәбәрдарлык сәясәте игълан ителде.

Татарстанда 1980 нче еллар азагы – 1990 нчы еллар башы милли үзаңның үсү чорына әйләнде. Иҗтимагый хәрәкәт бик нык сәясиләштерелде. Республикада Халык фронтының инициативалар үзәге (гамәлдәге хакимиятнең иң көчле оппонентларын берләштереп, КПСС диктатурасын җимерүгә чакырды), Татар иҗтимагый үзәге (ул елларда татар милли хәрәкәте лидеры иде), «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясе, «Азатлык» татар яшьләре берлеге барлыкка килде. Бөтен Татарстан митинглар, пикет-демонстрацияләр дулкынына күмелде. 1990 елның февралендә Казанда андый чаралар асылда һәр көн саен диярлек уза иде. Ул чагында КПСС өлкә комитеты беренче секретаре вазыйфасында эшләгән Минтимер Шәрип улы Шәймиев килеп туган сәяси вазгыятьне «үзгәртеп коруның фаҗигале этабы» дип бәяләде.

Әнә шундый гаять катлаулы социаль-икътисади шартларда уникенче чакырылыш республика Югары Советы эше башланды. Минтимер Шәймиев аның рәисе итеп сайланды.

> СССР Югары Советы 1990 елның апрелендә, автономияләрнең хокукын киңәйтеп, аларга союздаш республикалар белән бертигез дәрәҗәдә яңа Союз килешүен төзү буенча сөйләшүләрдә катнашу хокукы бирде. Милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда мөстәкыйльләшү процессы башланды. Әйтергә кирәк, аңа карата федераль хакимиятнең мөнәсәбәте анык түгел иде.

1990 елның июлендә ул чагындагы РСФСР Югары Советы Рәисе Борис Ельцин Казанга килгәч, тарихка кереп калган сүзләр әйтте: «Мөстәкыйльлекне күпме йота аласыз, шуның кадәр алыгыз». Икенче яктан, соңрак Татарстанны сепаратизм башында торучы буларак атый башлауларын да онытмаска кирәк. Ә республика игълан иткән дәүләт суверенитетын законлаштыру өчен референдумга әзерләнгәндә, Россия Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов «Известия Татарстана» газетасы хәбәрчесе белән әңгәмәсендә республика җитәкчелеген һәм Президент Минтимер Шәймиевне Мәскәүгә «тимер читлек»тә китерергә вәгъдә итте. Килеп туган хәлләр соңгы чиккә җитеп кискенләште.

Шуңа да карамастан, без бу мәсьәләне закон кысасында хәл итүгә ирешә алдык. Вакыйгаларның тарихи чылбыры болайрак: 1990 елның 24 августында Казанда Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итү таләбе белән митинг узды. Биш көннән соң ТАССР Югары Советы сессиясе әлеге мәсьәләне карый башлады. Зур бәхәсләр башланды. Килештерү комиссиясен оештырып, документның һәр маддәсе буенча аерым тавыш бирергә туры килде. 1990 елның 30 августында әһәмиятле хокукый акт кабул ителде. Ә инде

1992 елның мартында референдум үткәрелде. Анда күпмилләтле халкыбыз республика статусын үстерү омтылышын хуплап тавыш бирде һәм Декларация положениеләрен билгеләде. Шулай итеп, ТАССР Югары Советы 1992 елның 6 ноябрендә халык ихтыяры нигезендә республиканың яңа Конституциясен кабул итте.

Соңрак, Россия Федерациясенең яңа Конституциясе проектын эшләү барышында, Татарстан делегациясе берничә тапкыр Россиянең яңа Төп Законында республиканың дәүләт статусы үзенчәлекләрен исәпкә алу зарурилыгы турында тәкъдимнәр кертте. Тик, кызганыч, Конституцион киңәшмәдә катнашучылар аларны исәпкә алмады. Нәтиҗәдә Татарстан сайлаучылары Россия күләмендәге референдум барышында федераль Конституцияне хупламады, шунын белән аңа карата үзләренең мөнәсәбәтен белдерде. Соңрак килеп чыккан хокукый аңлашылмаучанлыклар нәкъ менә шуңа бәйле. Әмма алар Хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара эшләр тапшыру турындагы шартнамә кысасында хәл ителде. 2007 елның июлендә документның гамәлдә булуы озайтылды. Ә инде ул гамәлдән чыкканнан соң барлык мәсьәләләр федераль законнар кысасында хәл ителә.

**:: Конституцион хокук фәнендә, СССРда Конституцияләр бары тик сәяси иде, алар юридик үзенчәлекле документлар булып тормады, дигән фикер бар. Ә безнең Татарстан Конституциясе, Сезнеңчә, сәясиме, әллә юридик үзенчәлекле документ булып торамы?**

– Конституция – сәяси, хокукый һәм хәтта идеологик документ ул. Аның сәяси-хокукый документ буларак аталуы очраклы түгел.

Иң элек дәүләтнең Төп Законы бу. Аны барлык кешеләр үтәргә тиеш. Өстәвенә Конституциягә салынган юридик нормалар иң югары кыйммәткә ия. Ягъни кабул ителгән бер генә закон да Конституциягә каршы килә алмый, дигән сүз.

Конституциянең сәяси функциясе дәүләт сәясәте нигезләрен (халык хакимияте принциплары, сәяси күптөрлелек һәм күппартиялелек, кешеләрнең төрле сәяси хокуклары һәм ирекләре һ.б.) ныгыту һәм үстерүдә чагыла. Конституция нормаларының сәяси бәяләмәсе аларның идеологиясенә нык бәйле. Россия, шулай ук республика Конституцияләре идеологик һәм рухи күптөрлелек принцибына нигезләнә. Әмма Төп Закон һәрвакыт дөньяга билгеле бер карашны чагылдыра, иң мөһим кыйммәтләрне – кеше хокукын, демократик институтларны, хосусый милекне, икътисади эшчәнлек ирекен һәм Конституцион корылыш нигезен тәшкил итүче башка кыйммәтләрне игълан итә.

Россия Конституциясе һәрвакыт сәяси генә булды, дип әйтә алмыйм. Конституция – декларация генә түгел, ә илнең юридик һәм хокукый системасы үзәгендәге төп документ ул. Законнар һәм хокукый актлар шуның нигезендә кабул ителә.

Татарстан Республикасы Конституциясенә дә юридик, сәяси һәм идеологик төсмерләр хас. Моннан тыш республиканың Төп Законы болгавыр 1990 нчы елларда төрле сәяси һәм иҗтимагый көчләрнең үзара килешү үрнәге дә булып тора.

### Татарларны берләштерә

**:: Татарстан Конституциясенең 14 нче статьясы тулысынча республикадан читтә яшәүче ватандашларыбызга ярдәм итүгә багышланган. Бу нигезләмә милли үзаңны үстерүгә, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм милләтара мөнәсәбәтләрне үзара җайга салуга нииндирәк йогынты ясады?**

– Чыннан да, Татарстан үзенә шундый берләштерү бурычын алды. Эш шунда: татарлар – Россиядә сан ягыннан икенче урында торучы халык. Шул ук вакытта – илебез һәм чит илләрдә иң күп сибелеп яшәүче халык та. Республика милләттәшләребезгә мәдәниятне, гореф-гадәтне, телне саклауга ярдәм итүне үз бурычы дип саный.

Татар диаспорасы көчле булган төбәкләргә һәм чит илләргә ана телен өйрәтү буенча дәреслекләр, методик кулланмалар, ана телендә әдәбият җибәрелә. Республикада татарларның көнкүреше, мәдәнияте һәм традицияләре турында сөйләүче «ТНВ-Планета» спутник каналы эшләп килә. Һәр ел саен илебез төбәкләрендә һәм чит илләрдә Сабан туйлары уза.

Мәдәни хезмәттәшлек милләтара тынычлык һәм динара татулыкны саклау буенча зур эшнең бер өлеше булып тора. Аның нигезләре дә Конституциягә салынган.

**:: Сезнеңчә, республика Конституциясе ни дәрәҗәдә изге, кагылгысыз булып торырга мөмкин? Әллә аңа үзгәрешләр кертү, теоретик яктан гына булса да, гадәти эшкә әйләнә аламы?**

– Татарстан Республикасы Конституциясе гамәлдә булган утыз ел эчендә аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында уналты закон кабул ителде. Минемчә, бер өлеше федераль законнарга туры китерү зарурилыгына бәйле булганлыктан (Татарстан Конституциясенең федераль үзәкнекеннән бер елга алданрак кабул ителгәнлеген, шуңа күрә аның нигезләмәләрен исәпкә алмаганлыгын тагын бер кат искә төшереп үтәм), күп түгел бу.

Субъектларның законнар чыгару инициативасы буенча кайбер хокукларын киңәйткән үзгәрешләр бар. Без, аерым алганда, Төп Законны үзгәрту аша республика Прокуроры һәм Дәүләт Киңәшчесенә закон чыгару инициативасы хокукын бирдек, Дәүләт Киңәшчесенең, Татарстан Президенты тәкъдиме белән, Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнүен күрсәттек.

Конституциягә карата сакчыл мөнәсәбәт үрнәкләреннән берсе – 91 нче статья. Анда республика Президентын сайлау, кандидатка карата таләпләр турында язылган. 2005 елда Россиядә төбәкләр җитәкчеләрен турыдан-туры сайлау, субъектлар башлыкларын Россия Президенты тәкъдим итеп, аларны законнар чыгару җыеннары тарафыннан раслауга алыштырылды. Хакимият вертикален ныгыту зарурилыгына бәйле иде бу.

> Без Татарстанда моның вакытлы чара булырга мөмкин икәнен аңлап, 91 нче статьяны юкка чыгармадык, аның гамәлдә булуын гына туктатып тордык. Өстәмә рәвештә 91 нче статьяга 1 искәрмә керттеп, анда федераль законда кабул ителгән үзгәрешләрне күрсәттек. Федераль дәрәҗәдә турыдан-туры сайлауга әйләнеп кайткач, Татарстан Конституциясенең 91 нче статьясын кабат «эшләтеп җибәрдек» һәм 1 искәрмәсен, үз көчен югалткан, дип таныдык.

### Заман таләбе

**:: Шуңа да карамастан, бүген Татарстан Конституциясенә үзгәрешләр кертү котылгысызмы инде?**

– Әйе. Бу иң элек 2022 елда Россия Федерациясе Конституциясенә үзгәрешләр кертелүгә бәйле. Россиядә яшәүчеләрнең 78 проценты диярлек илүләм тавыш бирү кысасында әлеге үзгәрешләрне хуплады. Россия Конституциясенә федератив төзелешкә, Президент, парламент, хөкүмәт, суд хакимияте, прокуратура һәм җирле үзидарәгә кагылышлы 206 үзгәреш һәм өстәмә кертелде. Әмма иң мөһиме – илнең Төп Законы кеше хокукына игътибарны көчәйтте. Аерым алганда, хезмәткә түләүнең минималь күләме яшәү минимумыннан кимрәк була алмавы билгеләнде, пенсияләрне, социаль түләүләрне мәҗбүри индексацияләү гарантияләре һ.б. расланды.




Хәзер республикада Татарстан Конституциясен үзгәртү буенча тиешле эш алып барыла, башка төбәкләр тәҗрибәсе өйрәнелә, федераль үзәк белән консультацияләр үткәрелә. Бу эшне регламентта каралган вакыт эчендә төгәлләүне күздә тотабыз.

Гомумән алганда, Төп Закон, теләсә кайсы башка документ кебек үк, үзгәрергә мөмкин, дип уйлыйм. Әмма кешеләрнең теләге буенча, аларның үз киләчәген, ил киләчәген күзаллаулары буенча гына үзгәртелергә тиеш, дигән фикердә торам. Конституция – җәмгыятьтәге үзгәрешләрне бик тиз сизеп алырга тиешле җанлы документ ул. Конституция – үзгәртеп булмый торган юридик документ, дигән фикер, минемчә, дөрес түгел. Бу тарихи мисалларда аеруча ачык күренә. Элекке союздаш республикалар булган кайбер илләрнең, 2020 елдан, мөһим сәяси-хокукый вакыйгаларга бәйле рәвештә, Конституцияләре дә үзгәртелә. Ике ел элгәрәк Төрекмәнстанда Конституцияне реформалау төгәлләнде. Быел Белоруссия һәм Казахстан Конституцияләренә үзгәрешләр кертелде. Ел азагына кадәр Үзбәкстанның да Төп Законы үзгәртелү көтелә.

**:: Урамда очраган кешеләрдән: «Конституция турында нәрсәләр беләсез?» – дип сорасак, белемнәре бик чамалы булып чыгарга мөмкин. Әйбәтме бу, әллә начармы? Конституция «үзе турында белдерми» икән, димәк, «сиздермичә генә эшли». Әйтик, сулар һава кебек...**

– Бер яктан, чыннан да, шулай. Конституциядә халык тарафыннан гасырлар дәвамында булдырылган әхлакый кыйммәтләр урын алган. Бу – гадел хокукый дәүләт, хакимият бүленеше, законның өстенлеге, сәяси күптөрлелек, фикер хөрлеге, гуманизм... Әлеге күзлектән караганда, Конституция, чыннан да, «сиздермичә генә эшли», чөнки аның күп кенә нигезләмәләре, милли менталитетыбызның бер өлешенә әйләнеп, шулай булырга тиеш дип кабул ителә.

> Икенче яктан, республикада яшәүче һәрбер кешенең Төп Законны, үз хокукларын һәм бурычларын белергә, конституцион нигезләмәләргә таянып яшәргә-эшләргә тиешлегенә иманым камил.

**:: Элгәрәк, советлар чорында, һәрбер уку йортында кеше күрерлек урында СССР Конституциясеннән төп өземтәләр эленеп тора иде. Хәзер андый нәрсә юк. Дөресме бу?**

– Минемчә, әйбәт күренеш иде ул. Үсеп килүче яңа буында дөньяга караш, кеше хокукларына ихтирамлы мөнәсәбәт, законнарның тайпылышсыз үтәлергә тиешлеген аңлау булырга тиеш.

Әмма бүген Конституциядән өземтәләрне белү генә аз, яшьләрне хокукый киңлек кысасында яшәргә өйрәтү мөһим. Шуңа күрә 2009 елдан бирле Дәүләт Советы депутатлары, республика Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, укучыларның сәяси-хокукый культурасын, гражданлык позициясен булдыруга ярдәм йөзеннән, парламент дәресләрен үткәреп килә. Бу эш 13 ел эчендә үзен аклады.

**:: Фәрит Хәйруллович, Бөекбритания, Канада, Яңа Зеландия, Швеция, Израиль кебек Конституциясез дә рәхәтләнеп яшәүче, алга киткән дәүләтләр бар. Конституциянең әһәмияте нәкъ менә Төп Закон буенча яшәү зарурилыгына түгел, бәлки тегеи яки бу илләр, халыкларның традицияләренә күбрәк бәйле ме икән әллә?**

– Сез хаклы. Конституциягә ия булмаган җирде ил бар. Сезнең исемлеккә тагын Ливия һәм Сан-Мариноны өсти алам. Кайбер илләрдә конституцион хокук нормалары төгәл генә билгеләнгән бердәм документ юк. Бу феномен «язылмаган Конституция» дип йөртелә. Биредә законнар, конституцион гадәтләр җыелмасын туплаган «прецедентлы хокук» турында гына да сүз бармый. Мәсәлән, Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм Бәхрәйндә киң таралган «мөселманнар хокукы» турында да әйтергә мөмкин. Аның төп үзенчәлеге – дини идеология һәм әхлак белән тыгыз элемтәдә булу.

Һәрхәлдә, мондый илләрдә Конституция күздә тотылмаса да, аларның барыбер ниндидер Төп Законнары бар. Өстәвенә бүгенге дөньяда юридик-хокукый структураларның бергә кушылуы күзәтелә. Мәсәлән, безнең илдә суд органнарының роле көчәя, шул рәвешле «прецедент»лар пәйда була. Ә Конституциясез илләрдә чынбарлыкны законнарга салу тенденциясе торган саен күбрәк күзәтелә.

### Бердәмлектә – көч

**:: Әңгәмәбез Халыклар бердәмлеге көненә туры килде. Бәйрәм нигезенә салынган XVII гасыр вакыйгалары бүгенге шартларда яңача яңгыраш тапты, дип уйламыйсызмы?**

– Әйе, 4 ноябрьдә билгеләп үтелгән дәүләт бәйрәменең чишмә башы 1612 елгы бик зур вакыйгаларга килеп тоташа. Ул чагында халык ополчениесе, халыкның бер йодрыкка берләшү үрнәген күрсәтеп, Мәскәүне илбасарлардан азат итә.

Безгә, өченче меңьеллыкта яшәүчеләргә, ул вакыйгалар, әлбәттә инде, бик еракта калган кебек тоела. Әмма шуны беләбез: нәкъ менә Россиянең күпмилләтле халкының бөек максатка ирешүдәге бердәмлеге, илебезне иксез-чиксез сөю һәм ватанпәрвәрлеге Ватаныбызга тарихның кыен сынауларына бирешмәскә ярдәм итә.

> Бүген дә илебез авыр чор кичерә. Әмма Россия һәрвакыт үз мәнфәгатьләрен яклау һәм саклау юлларын тапты. Нәкъ менә хәзер бөтен җәмгыятебезнең, бергә тупланып, бердәмлегебезне күрсәтүе, ил җитәкчелеге кабул иткән карарны хуплавы чиктән тыш мөһим. Бердәмлектә – көч. Татарстанның күпмилләтле халкы тарихи үсешенең төрле этапларында моны күп тапкыр раслады.

**Әйтеп кенә бактым**

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

# *Баш фәлсәфәсе*

Инде ничә еллар киеп йөргән кепкам быел башны кыса башлады. Моны дусларга да әйттем. Берсе: «Яңгыр астында киеп йөргәнсеңдер, утыргандыр», – диде. Икенчесе: «Димәк, акылың арткан да, башың зурайган», – дип көлде. Көлүен көлде дә, бик уйландырды аның әйткәннәре. Әллә бәндә баласы картайган саен акыллырак була бара микән? Алай булса, ни өчен өлкән яшьтәгеләр турында «акылы киткән» дигән сүзләр шактый еш ишетелә?

Бер уйлаганда, баш, кем әйтмешли, тәпсез мичкә түгел, бөтен мәгълүматны сыйдырып бетерә алмый. Шуңа күрә өлкән кешенең хәтере бетәдер дә, бу үз чиратында яңа мәгълүмат керү өчен урын бушату кебек буладыр. Инде килеп, бик мәгълүматлы, акыллы булу башның зурлыгына ни дәрәҗәдә бәйле икән? Ленин ничәнче размерлы кепка киде икән? Интернетта «диаметры 26 см» дип язылган үзе, әмма размерын исәпләп чыгарырга башым җитми.

Бөек юлбашчы кечкенә башлы булмагандыр. Балачакта безнең авылда зур башлы кешегә «Ленин башлы» дип әйтәләр иде. Бер кызыклы хәл искә төште әле. Безнең өйдән ерак түгел волейбол мәйданчыгы бар иде. Анда укытучылар, авыл яшьләре, югары сыйныф укучылары «туп сукты». Волейбол мәйданчыгына якын гына урнашкан йортта ялгыз карчык – Хупҗамал апа яшәде. Сугылган туп еш кына аның капкасына «шап» итеп килеп бәрелә дә, Хупҗамал апа шул тавышка йөгереп чыгып, кулындагы без белән тупны тишә иде. Берсендә туп шулай капкага таба тәгәрәп китте, туп артыннан Чулак Әхмәт малае Рәдиф йөгерә, икенче яктан без белән коралланган Хупҗамал апа чаба. Болар икесе бер үк вакытта тупка ябыштылар да тартыша башладылар. Рәдиф, әлбәттә, көчлерәк иде, ни дисәң дә, буй җиткән үсмер егет бит. Әби кулыннан тупны тартып алуы булды, Хупҗамал апабыз бөтен дөньяга ишетелерлек итеп: «Шәйхулла, Шәйхулла, син Чулак Әхмәт малаен Ленин башлы дигән идең, Ленин башлы түгел, фәлән башлы икән ул!» – дип кычкырып җибәрде. Шәйхулла абый дигәнебез мәктәпнең завучы була инде. Бик яхшы укыганга Рәдифне ул да, башкалар да «Ленин башлы» дип йөртте, ә бу хәлдән соң аңа «кабак баш» дигән кушамат тагылды. Баш белән бәйле нинди генә гыйбарәләр юк бездә: «таш баш», «чүбек баш», «башсыз»... «Тавык мие эчкән нәрсә» дигәне дә баш, ягъни тавык башы белән бәйле һәм болай әйтү кечкенә башта минең дә кечкенә булуын аңлатадыр, мөгаен.

Кызык, акыл баш миенең зурлыгына ни дәрәҗәдә бәйле икән? Белгечләр фикеренчә, башның һәм баш миенең зурлыгы акылга әллә ни йогынты ясамый. Шул ук вакытта акылны элек-электән маңгай зурлыгы белән чамалаганнар һәм уйлау, фикерләү сәләте түбән булганнар турында «тар маңгайлы» дип әйтү гасырлар буе яшәп килә.

Белгечләрнең күбесе исә акылның камиллеген, башның, баш миенең зурлыгы белән түгел, ә минең төзелеше белән бәйли. Монысы дөреслеккә күбрәк туры килә кебек.

Минем кепкамның башны кысуы да акылым арту белән бәйле түгел дип уйлыйм. Кайчак Әнгам Атнабаевның бер шигырендәге юллар искә төшә дә, куркып та куям. «Шулай безгә акыл керә микән, әллә чыга микән кергәне» дип язган иде ул. Мөхтәрәм шагыйрьнең тел төбендә башка уй иде: без бу дөньяда күпме яшәүгә карамастан, чынбарлыкны ничек бар шулай кабул итәргә тиеш. Масаеп, кәттәләнеп яшәү кешене боза. Тирә-юньдәгеләр синең һәр гамәлеңне күзәтләп торса, син үзеңне һәрвакыт хаклы итеп тоя башлыйсың. Син – дөнья тоткасы. Син һәр нәрсәгә үзең баш, үзең түш, янәсе. Ә тормышта алай була алмый. Ходай барыбызны да тигез яраткан. Һәр кешенең генә түгел, һәр гаилә, һәр халыкның – үз яшәү рәвеше. Шушы тигезлек бозылса, дөнья бутала башлый. Моның шулай икәнен бүген үзебез үк күреп торабыз.

Әгәр Хупҗамал апа исән булса, бөтен дөньяга баш булырга теләүчеләргә нәрсә дип кычкырыр иде икән? «Син Ленин башлы түгел, фәлән башлы икән», – дип әйтми калмас иде.

Кешегә баш бүрек киеп йөрү өчен бирелмәгән. Кепканы кулымда әйләндергәләп карыйм да, әллә кирәкмәгән уйлар кереп тулып, башымны зурайттылар микән, дип уйлап куям. Болай уйлау көлке, әлбәттә, минем яшьтә керәсе кергән инде, «амбар» тулган. Чыгасы да чыгар, әмма изге ниятләр, яхшы уйлар калсын иде.

# БАЙЛЫК ТУРЫНДА БАЛЛАДА

Халыкара валюта фонды җитәкчесе Кристалина Георгиева моннан берничә көн элек: «Дөнья икътисады 2023 елда хәзерге кыеннан тагын да авыррак заманга күчә», – дип белдерде. Ул әйтмәсә дә, мәгълүм инде: финанс базарларында җимереклек көчәя, куыклар шиңә, олигархик капитал ияләре йөз миллиардлаган долларлык активларыннан колак кага.

pixabay.com

Минем иң соңгы хәбәр: Швейцария Үзәк банкы быелның тугыз аенда үзенең 115 еллык тарихында иң зур зыянны күрде. Югалтуларның күләме – 142,6 миллиард доллар. Ул илнең иң ышанычлы дип саналган хосусый банклары да зур югалтулар кичерә. Төп сәбәбе – спекуляция нәтиҗәсендә сатып алынган кыйммәтле кәгазьләрнең чүпкә әйләнүе. Әйе, әйе, глобаль капитализм бөек түнтәрелеш стадиясенә кереп бара. Тик торганда гына Швейцария банклары турында кузгалтмадым сүзне, чөнки алар бөтен Җир шарында иң ышанычлылардан санала иде. Банклар зыянга эшли башласа, ни буласын беләбез бит инде: депозитлар «яна». «Татфондбанк»ның җимерелеп төшкәнен хәтерлисездер әле. Татарстандагы иң ышанычлы ике банкның берсе булып санала иде ул. Шуңа күрә кече бизнес үз хисабын шунда ачарга тырышты, физик затлар да аның депозитына аз акча салмады. Соңгыларының гамәле банкның процентларны күп түләве белән бәйле иде. Хәтерлим әле: минем бер танышым бар эшләгән акчасын айныкын айга шул банк депозитына салып барды. Банкның хәле мөшкел булуын аңлаганга күрә, кисәттем аны: «Акчаңны ал депозиттан, бердән, ул – Аллаһ тарафыннан тыелган гамәл, икенчедән, банк озакламый түнәчәк», – дидем. Тыңламады инде. Акчасы күп иде, процентлар да өстәлеп, шактый зур сумма җыелды, нәфесне котыртта, мавыктыра торган уенга әверелде. Финал билгеле инде: йөрәк белән хастаханәгә кереп яту, зур акчадан колак кагу ачысын кичерү. Акчаның иминиятләштерелгән өлешен кайтарып бирделәр соңыннан. Физик затлар өчен андый гарантия бар иде. Кече бизнес ияләре исә бөлделәр, эш кайвакыт гаиләләр таркалуга кадәр барып җитте. Менә мондый хәлләр дөнья күләмендә ешаячак, Халыкара валюта фонды рәисе безгә шул хакта хәбәр итә, фонд базарларында еш кабатлана башлаган җимерелүләр дә шул хакта сөйли.

Кешеләр ни өчен фонд базарларында уйный һәм ни өчен банк депозитларында акча туплый, яисә ни өчен кредит җыялар? Берничә төп сәбәбе бар бу хәлләрнең. Беренчесе – курку. Кризис булыр да эшсез калырмын, картлык көнемдә ашарыма булмас, сәламәтлегем югалып, шулай ук ризыгым киселер дигән хәсрәт акчаны саклау һәм ишәйтү юлларын эзләргә мәҗбүр итә. Кемдер кысып җыйган акчасын илтә депозитка, кемнәрдер «алтын парашют»лар ярдәмендә эләккән «калҗа»ны сала. Киләчәкне финанс ягыннан ныгытырга телиләр. Курку – бик көчле этәргеч, бик куәтле двигатель. Әмма киләчәк көнне югарыда әйтелгәнчә кайгырту ризыкны гарантияләми. Киресенчә, һәлакәткә илтә. Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы – Аллаһ кулында. Менә шул гарантиягә иман китерсәң, кризистан курку юкка чыга. Банк депозитында мал тупларга тырышу мәгънәсезгә әйләнә.

Әмма ризыкның гарантияләнгән булуы кул кушырып утырырга сәбәп түгел, чөнки бу дөньядагы өлешең эзләп, көч куеп табыла. Аллаһы Тәгалә сиңа сәләт, көчкуәт, сәламәтлек кебек состав өлешләрне бирә дә тормышыңны сиңа мал табу мөмкинлеге биргән вакыйгалардан төзи. Син шулардан файдаланасың. Ялкаулансаң, югалтасың инде, әлбәттә. Ялкаулык – гөнаһ. Гөнаһлары өчен кешеләр ризыклары кимү белән җәзаланалар. Галәмнәрнең Хуҗасы безне мал югалту белән сынап та торачагын әйтеп кисәтә, ягъни кризислар – котылгысыз. Кризис вакытында иман иясе Аллаһның гарантиясенә инанган хәлдә сабыр итә, күңелгә кергән курку вәсвәсәсеннән арынырга тырыша.

Курку бик көчле гипноз хәленә куя адәм баласын. Телефон мошенниклары нәкъ шуны файдаланып гипнозлыйлар да инде. 29 октябрь көнне генә Югары икътисад мәктәбе укытучысы Михаил Карповны үзләрен «Үзәк банк хезмәткәрләре» дип атаган кешеләр 2 миллион сум акчасыз калдыра. Телефоннан бирелгән әмерләргә буйсынып, ул шул суммадагы кәгазь акчаларын курьерга тапшырган һәм, эш үткәннән соң гына айнып, полициягә мөрәҗәгать иткән. Карповның телефон мошенниклары һәм аларның алдау ысуллары турында ишеткәне булмаган дип уйламыйсыздыр инде. Зур банкларның вице-президентлары, Владимир Путинның матбугат секретаре Песковның кызы һәм башка бик күп дәрәҗәле кешеләр капты аларның гамәлләренә. Соңгы көннәрдә генә "Газпром"дагы бер менеджерның 20 яшьлек кызы 49 миллион сум акчасын шулар хисабына күчерде. Телефон аша гипнозлау бик киң таралды хәзер, шуңа күрә таныш булмаган номерлардан шалтыратуга җавап бирмәгез. «Мине алдый алмаслар», – дигән уйны баштан чыгарып ташлагыз.

Киләчәкне тәэмин итәргә тырышып, депозитларда җыйган акчаның күпчелегенә файдаланылмый. Киләчәк үзе гарантияләнмәгән бит әле. Бу ел башыннан гына күпме компаниянең топ-менеджерлары вафат булды, исәбен алып бармадыгызмы? Күбесе серле һәм фаҗигале рәвештә һәлак булды. Җыйган маллары күп иде, хәзер ул малларны телефон мошенниклары җилгәрә.

Барлык рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән ысуллар белән байлык тупларга омтылуның икенче механизмы – көнчелек. Башкаларны узарга тырышу. Бик мәгънәсез ярышка чыгара бу адәм балаларын. Пәйгамбәребез үзенең бер хәдисендә мөселманнарны бу хакта кисәтә: «... Аллаһ белән ант итәм, – ди, – мин сезнең фәкыйрьлегегездән курыкмыйм, үзегезгә кадәр яшәгәннәр ирешкән кебек дөнья байлыкларына ирешерсез дә, бер-берегез белән үзегезгә кадәргеләр узышкан төсле узыша башларсыз һәм бу сезне аларны һәлак иткән кебек һәлак итәчәк». Бу кисәтү безнең көннәрдә тормышка ашты. Үткән тәүлекләрдә генә Илон Маск «Твиттер»ны сатып алды бит әле. АКШ Сенатының бер вәкиле, сенатор Крис Мерфи бу вакыйганы, АКШның милли куркынычсызлыгына янау дип, тикшерү үткәрергә чакырды. Баксаң, 44 миллиард долларлык бу спекуляциягә Согуд короленең гаилә әгъзалары үзләреннән байтак өлеш керткән икән. Бай мөселман илләренең фонд базарында пирамида өю һәм куык кабарту белән актив шөгыльләнүләре берәүгә дә сер түгел. Шулай булгач, якынлашып килүче һәлакәт бер илне дә аямаячак.

Сәхабә Сәгдә бинт Гауф-Тәлхә ибн Губәйдуллаһның хатыны менә нинди истәлек калдырган: «Бервакыт Тәлхә төнлә бик борчылып уянды һәм мин аннан сорадым: «Сине ни газаплый?» «Бик күп акчам җыелды, шул тынгысызлый», – дип җавап бирә ире. Хатыны иренә әйтә шуннан соң: «Соң син аларны фәкыйрьләргә өләш». Шулай эшлиләр дә. Тукталыйк та уйланыйк әле шушы эпизод турында. Акчага безнең мөнәсәбәт һәм хатыныбызның карашы ничек булыр иде икән? Аның күплегенә сөенер идек, бары тик аңа ниләр алырга һәм ничек сакларга дигән сорау гына борчыр иде безне. Хатынга әйтсәк, ул да: «Тегене алыйк, моны алыйк», – дип башыбызны катырыр иде. Аллаһ каршында җавап бирүне уйламас һәм аннан курыкмас идек. Менә шуңа күрә Җир шарында яшәүчеләр, бердәм рәвештә кризистан куркып, стресс кичерәбез дә инде.

Мәңгелек тормыш өчен кайгырасы урынга, тиз үтүче дөньяның кадерсез байлыгы өчен ут йоту безне алдагы елларның бөек һәлакәтенә алып бара да инде. Бу юлларның авторыннан: «Син әйткән алтын заман кайчан җитәчәк?» – дип сораучылар бар. Кайчан кешеләр бер сәҗдәне бөтен дөнья байлыгыннан өстен күрә башлыйлар, шул чакта бәрәкәтле муллык чоры башланачак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

# КАДЕРЛЕ КАВЕМ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

### Барын бар, тик...

Россия Мөселман хатын-кызлар берлеге рәисе, Гаилә кору һәм саклау үзәге директоры, ячы Наилә Җиһаншина, бар нәрсә дә тәрбиядән һәм балаларны гаилә коруга әзерләүдән башлана, ди. Ә бу җәһәттән эти-әниләр арттырып та җибәрә: кыз үстерүчеләр «сиңа ирең тиеш» дип иркәләсә, ир бала багучылар киресен тукый.

– Шуңа игътибар итми мөмкин түгел: хәзер ир-атлар күпкә көчсезрәк. Әниләре белән танышканда сизелә бит: аларның көчле булуы аркасында, малайлары йомшак булып үсә. Әни бар нәрсәне дә белә, бар нәрсәгә юнәлеш бирә, әни ничек куша, шулай була... Алай ярамый! Әни өстенлек итеп торучы көч булганда, ир бала көчсез булып үсә, чөнки ана моңа барлык шартлар тудыра. «Улым, син көчле, син үзең хәл итәргә тиеш, мин сиңа ышанам, булдырасың», – дисен иде ул. Әни шушы фигыльләрне кулланырга тиеш. Куллана белсә, малай чын ир булып үсәчәк. «Улым, мин әйткәнчә булырга тиеш», – дип тәрбияләгән очракта, бу ир бала үз гаиләсендә шуны ук хатынныннан көтәчәк. Ә кызлар андыйны яратмый, – ди Наилә Җиһаншина.

«Нинди ир-ат кирәк?» дигән сорауга, танылган ячы янына үз тиңен эзләп мөрәҗәгать иткән кызлар бер төрле җавап бирә икән. «Кызларга көчле ир-ат кирәк. Сүз авырлык, тән төзелеше, кыяфәт турында бармый. «Подкаблучник» та булмасын ул. Җаваплылыктан курыкмавы, тиеш урында кирәкле карар кабул итә алуында күренә ир-атның көче. Һәм, әлбәттә, рух ныклыгында. Менә шул рух ныклыгы дигәне җитми бүген», – дигән фикердә Наилә Җиһаншина.

Оясында ни күрсә, очканда шул булыр. Татарстанның һәм Россиянең атказанган табибәсе, медицина фәннәре кандидаты, невролог Дусинә Әхмәдуллина ир бала тәрбияләгәндә әнә шуны истә тотарга кирәк дигән фикердә. Шул очракта, күз алдында үрнәк булганда, ничек үстерим икән, дип баш ватасы да түгел.

– Ир бала тәрбияләү буенча аерым рецепт юк. Мин үскән гаиләдә дә, үзем корган гаиләдә дә үрнәкләр булды, менә шулар тәрбияләгәндер дим, – ди табибә. – Улым Президент Аппаратында эшләдә. Аның белән бергә эшләүче бер ханым миңа улым аша гел сәлам әйтеп, хәл-әхвәл сорашып торды. Берсендә улым, шалтыратып: «Әнием, фәлән ханым синең белән сөйләшергә тели», – дип, трубканы шул кешегә бирә. «Сез бу улыгызны ничек тәрбияләдегез икән? Мин Аппаратта эшләүче барлык ир-атларны да сезгә тәрбиягә җибәрер идем!» – дип кызартты ул мине.

Тагын бер очрак балачагыма бәйле. Мактанып әйтүем түгел, әмма әтием дә, әнкәй дә Актанышта хөрмәтле кешеләр булды. Әтигә дә, әнкәйгә дә киңәш сорап килүчеләр аз түгел иде. Аларның да безгә: «Болай булыгыз, болай яшәгез», – дип утыртып өйрәткәне булмагандыр. Әмма тормышлары белән үрнәк була беләләр. Менә тагын бер мисал: безнең әтиебез янына бер егет йөгереп килде дә: «Шамил абый, фәлән җирдә ике егет нәрсәдер бүлешә алмый, барып кына кил инде», – дип үтенә башлады. Әтиебез гомер буе нидер корып, өйне матур-пөхтә тоту белән шөгыльләнде. Ишегалдында һәрвакыт такта булыр иде. Шунда килеп, тактаның кечкенә генә бер өлешен каерып алып, теге егетләрне аерырга китте. Әтиебезне күргәч: «Шамил абый, булды-бетте», – дип, низагларына нокта куйдылар. Мин дә үз гаиләмдә алар кебек булырга тырышканмындыр. Улым миңа еш кына: «Әнием, башкалар мине мактый, син гел орышасың», – дип әйтә иде. Мин исә: «Улым, мин сине барысыннан да артыграк яратам, орышмыйм, юнәлеш кенә бирәм», – дип җавап бирә идем. Улым белән мөнәсәбәтләребез шөкер генә. Тагын бер нәрсә: малайда әти ни әйтер икән дигән уй да булырга тиеш. Ирем: «Соңрак сөйләшербез», – дип әйтә торган иде. Әнә шул «соңрак сөйләшү» азрак куркытып тора иде инде балаларны.

Табибә фикеренчә, хатын-кызның идарәне үз кулына алырга, мөстәкыйль булырга омтылуы да ир-егетләрнең рухи яктан көчсезләнүенә китерә. «Хатын-кыз – барысын да булдыра торган зат. Бу сер түгел. Әмма, булдырам, дип кенә булмый! Калкан, таяныч, терәк ул – ирләребез», – ди Дусинә ханым.

Яңа Чишмә районы Чертуш авылыннан Рәмзия Мусина көчле ир-ат тәрбияләү серен шулай ук яхшы белә. Көрәш дөньясында танылган спортчы Булат Мусинның әнисе ул. Егетнең ир-ат булып үсүендә хезмәт тәрбиясе мөһим, дигән фикердә Рәмзия ханым.

– Ир-атка кадер буыннан буынга, гаиләдән гаиләгә тапшырыла дип уйлыйм. Бабай-әби, әти-әниебез мөнәсәбәтләрен күреп үстек. Әти сүзе безнең өчен закон булды. Ашарга утырганда, табынга чыккан ризыкка да иң элек әти сузыла иде. Әтидән узмадык, – ди ул. – «Әтиегез белән киңәшләшик», «ул ни әйтер», дим мин дә балаларга. Улым Булатны яхшы беләсез инде. Без балаларыбызга кечкенәдән хезмәт тәрбиясе бирдек. Әтиләре дә һәр башлангычларын хуплап торды. Алар белән бергә йөгерде дә, бөтен эшне дә бергәләп эшләделәр. Булатны тәрбияләүдә атасының роле зур. Булат – безнең сабыр, нык ихтыярлы кеше.

Рәмзия Мусина, ил-көндә барган хәзерге вазгыятькә аналар бигрәк тә әрни, ди. «Солдатларны озатканнарын карыйм да, ир-егетләрнең кадерләре тагын да артуын аңлыйм. Ир-атларсыз дөнья таянычсыз бит ул. Барысы да исән-сау булсыннар иде», – дигән теләктә әңгәмәдәшебез.

### Саннар ни сөйли?

2022 елның 1 гыйнварына булган мәгълүматларга караганда, илдә яшәүче 145557576 кешенең күп өлеше хатын-кызларга туры килә. Аларның саны – 77,9 млн. Ир-атлар, аңлашылганча, азрак – 67,7 млн. 1 мең ир-атка, уртача алсак, 1152 хатын-кыз туры килә дигән сүз. Ике төбәктә генә ир-атлар хатын-кызларга караганда күбрәк икән. Бу – Камчатка крае һәм Чукотка автономияле округы. Әмма хатын-кызлар санының күплеге барлык яшь категориясе өчен дә хас түгел. Росстат мәгълүматларына караганда, ул бары тик 36 яшьтән башлана.

Үзгәрешләрнең тамырларын барлый башласаң, аларның ХХ гасырның беренче елларында ук башлануына игътибар итәргә мөмкин. Бу үсеш алган илләрдә гүзәл затларның хезмәт базарына керүе белән бәйле. Ә инде хатын-кыз акча эшли башласа, аңа традицион гаилә кыйммәтләре азрак тәэсир итә башлый дигән сүз. Бу – бер яктан караганда. Икенче яктан, гүзәл затның бурычлары да ишәя: аңа гаилә һәм эш арасында алтын урталык сакларга туры килә.

«Мине табу кыен, югалту җиңел, оныту тагын да авыррак» дигән мәгълүм мәзәкне хәзерге вазгыятьтә ир-атларга карата да кулланып булыр иде төсле. Кызганыч, безнең илдә ир-атларга мөнәсәбәт кенә түгел, аларның үзләренә карата мөнәсәбәте юнәлешендә дә эшлисе эшләр җитәрлек. Әйтик, ир-атлар мәдәни чараларга хатын-кызларга караганда сирәгрәк йөри (йөрсә дә, хатын алып барганга гына), еш кына тышкы кыяфәтенә игътибар бирми (йә чамадан тыш игътибар итә), аз укыйлар, эмоцияләрен аңлата, тышка чыгара белмиләр (ачу һәм курку хисләреннән кала), социаль җаваплылыктан качалар. Бу инде – алар турында «юньлеләре калмады» дигән фикерне тагын да тирәнәйтү, калыплаштыру өчен бер сәбәп тә.

Гаилә психологы Роман Винилов әйтүенчә, ир-атларга үзләрен һәм үз ихтыяҗларын тормышка ашыру бик мөһим. Моңа өстәп, үз ишләре белән булу, дөрес мохит формалаштыру да кирәк. «Ир-атлар үзләрен кая куярга белмәсә, чикләсә, хис-кичерешләрен яшерсә, билгеле бер вакыттан соң бу психологик һәм физиологик авыруларга да китерергә мөмкин. Болар – иртә картаю, чирләр, тестостерон кимү. Нинди генә чор килсә дә, ир-ат үзенең бәйсезлеген, кыенлыкларны җиңә алуына, көченә ышанычка мохтаҗ булып кала», – ди ул.


Илдар Мөхәммәтҗанов

**Малай-шалай кайчан ир-ат була?**

*Бу һәм башка сорауларга психолог Галия ГЫЙМАДИЕВА җавап бирде.*

**:: Психология күзлегеннән караганда, малайны ничек чын ир-ат итеп үстерергә?**

– Асылда, бу – бик катлаулы сорау. Болай-болай эшлә дә, шундый нәтиҗә чыгачак дигән әзер формуласы юк аның. Әмма, һичшиксез, шуны аңларга кирәк: балалар ниндидер үрнәктә үсә. Ир балаларга да чын ир-ат ничек булырга тиеш икәнен күрсәтүче үрнәк кирәк. Тәрбиядә ата кешенең роле зур булуын билгеләп үтмичә булмый. Бу тәрбия – үзгә. Хатын-кыз ул – хис, эчке дөнья, җылылык. Ир-ат энергиясе исә тышкы дөнья, җәмгыять, максатчанлык турында. Кызмы-малаймы – балага икесен дә күреп үсәргә кирәк.

Хәзер ирек күбрәк. Әмма барысы да бу иреккә әзер түгел. Асылда аңа психик яктан әзер шәхесләр күп түгел, күбесе – аң белән үсмерлек чорында. Еш кына андыйлар югалып кала. Ир-атлар да ни теләгәннәрен, кая хәрәкәт иткәннәрен аңламый.

**:: Шунысы да бар: күп кенә гаиләләрдә малай тәрбиясе белән әниләр генә шөгыльләнә. Тагын бер кызганыч күренеш: ир балалар тулы булмаган гаиләләрдә үсә...**

– Бу очракта хатын-кыз зирәклеге дигән төшенчә бик мөһим роль уйный. Гаиләдә хатын-кыз әни дә, әти дә була алмый – шуны аңларга кирәк. Өстәмә җаваплылык алырга кирәкми. Бу зыянга эшли. Асылда, малай өчен ир-ат үрнәген табарга кирәк. Ата-ана аерылышкан икән, баланы бу мөнәсәбәтләр көрәшенә кыстырырга кирәкми, әлбәттә. Бала әнидән дә, әтидән дә баш тарта алмый. Әти дә, әни дә – аның аерылгысыз өлеше. Әгәр дә аерылышканда дустанә мөнәсәбәтләр саклап кала алгансыз икән, бу яхшы. Шуны аңларга кирәк: ир һәм хатын аерылыша, әмма бала өчен әти һәм әни дигән кешеләр кала!

Бу да барып чыкмаса инде, хатын-кыз башка үрнәк эзли. Абыйлар, ир туганнар, гаилә дуслары, тренерлар үрнәк була ала. Хәзер малайлар өчен лагерьлар да бар. Ир-атлар мохитенә кушылу өчен, бу да – яхшы мөмкинлек.

«Нишләргә?» – дигән сорауга килгәндә, малайларга кечкенәдән үк җаваплылык хисен сеңдереп үстерергә кирәк. Гаепләү, «тиеш» дип түгел, ә «бу шәп», «бу егетләрчә» дигән хис аша. Синең сүзең, синең карарларың шундый-шундый нәтиҗәләргә илтә, дип аңлатырга. Тәнкыйтьләү, «мин сиңа әйттем бит» дигән сүзне онытырга. Ир балага ышанырга кирәк. Ул ир-ат характеры формалашканда бик мөһим.

Егетләрнең тышкы дөньяга кызыксыну көчен куәтләп торырга кирәк. Статистикага карасаң, бик күп ачышларны ир-атлар ясаган. Аларның табигатьтән бирелгән кызыксыну ирәге бар. Малайларга комфорт зонасыннан аз гына чыгып керү файдага гына.

**P.S.** Ноябрьнең беренче шимбәсендә СССРның беренче һәм соңгы Президенты Михаил Горбачев тәкъдиме белән Бөтендөнья ир-атлар көне билгеләп үтелсә, 19 ноябрьдә – Халыкара ир-атлар көне дигән бәйрәм дә бар икән. Аерма эзләп баш ватмагыз, алдарак язуыбызча, асылы шул ук кала аның. Ир-атларның да җенес ягыннан кимсетелүенә, гаиләдә һәм бала тәрбияләүдә роленә, сәламәтлегенә, рухи һәм физик, социаль иминлегенә игътибар кирәклеген кабат искәртүебез иде максатыбыз. Язманы да ир-атларга хатын-кызлар күзлегеннән карап әзерләдек. Гүзәл затларга һәрвакыт читтән яхшырак күренә бит инде, шулаймы? Әлбәттә, форсаттан файдаланып, котлавыбыз да инде бу! Һәрвакыт терәк, кирәк, кадерле булыгыз, егетләр!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

## 7 ноябрь | Дүшәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Народная игрушка 6+
01.05 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Лирон Хәмидуллин турында телеочерк 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 12+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Максим Матвеев. «ТРИГГЕР». Новые серии 16+
23.45 «Большая игра» 16+
00.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова, Светлана Колпакова в телесериале «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
23.00 Премьера. «ОСВОБОЖДЕНИЕ». Фильм Андрея Медведева 16+
00.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

### МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. АСА. Эдуард Вартанян против Юсуфа Раисова. Трансляция из Москвы 16+
07.00, 10.00, 13.00, 16.40, 22.40 Новости
07.05, 14.25, 19.40, 21.55 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 23.15 Футбол. МИР. Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.25 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
13.55 Футбол. Жеребьёвка 1/8 финала Лиги чемпионов. Прямая трансляция из Швейцарии
14.55 Футбол. Жеребьёвка раунда плей-офф Лиги Европы. Прямая трансляция из Швейцарии
15.30 Бокс. Bare Knuckle FC. Реджи Барнетт против Джина Эрреры. Трансляция из США 16+
16.45 «Громко». Прямой эфир
17.55 Футзал. Товарищеский матч. Таджикистан – Россия. Прямая трансляция из Таджикистана.
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – «Пари НН» (Нижний Новгород). Прямая трансляция
22.45 Тотальный футбол 12+
00.20 «Любить Билла». Док. фильм 12+
01.20 Профессиональный бокс. Альберт Батыргазиев против Франклина Манзанильи. Трансляция из Москвы 16+
03.00 Новости 0+
03.05 Футбол. Чемпионат Германии. «Фрайбург» – «Кёльн» 0+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
22.00, 00.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
00.20 Борис Галкин. «ОТСТАВНИК» (S) 16+
01.45 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.10 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча». «Разорванные нити» 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «ОДНО ТЁПЛОЕ СЛОВО» 16+
19.00 «САШИНО ДЕЛО» 16+
22.40 «Порча». «Секрет ингредиента». «Холодная постель» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.20 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.35 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+

### ЗВЕЗДА

05.00 «ВНИМАНИЕ, ГОВОРИТ МОСКВА!» 3-я и 4-я серии 16+
06.30 «7 ноября – День проведения парада на Красной площади в 1941 году». Док. фильм. Премьера! 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА». 1-я серия 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.35, 03.35 «Москва фронту». Док. сериал 16+
18.50 «Предвидение космоса». Док. сериал. «Эскадра ракет». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал. «Экономические войны против Советского Союза» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.45 «СЫН ЗА ОТЦА…» 16+
02.05 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+

## 8 ноябрь | Сишәмбе

### ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

### ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 Телефильм 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля». (Татар телендә) 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45, 05.35 «Онытa алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Владимир Вавилов. Дом милосердия 12+
00.45 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

### ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар». Гәрәй Рәхим чыршысы 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20, 21.25 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 12+
19.20, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

### 1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. «Триггер». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

### РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова, Светлана Колпакова. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

### МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 16.20, 20.20 Новости
07.05, 14.20, 19.40, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25, 16.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
16.55 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
17.55 Футзал. Товарищеский матч. Таджикистан – Россия. Прямая трансляция из Таджикистана
20.25 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Эмполи». Прямая трансляция
22.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Вердер». Прямая трансляция
01.20 Смешанные единоборства. АСА. Эдуард Вартанян против Юсуфа Раисова. Трансляция из Москвы 16+
03.00 Новости 0+
03.05 «Рождённые побеждать. Игорь Нетто» 12+
05.00 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

### НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» (S) 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
22.00, 00.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
00.20 Премьера. «Англия – Россия. Коварство без любви». «Чисто английская провокация» (S) 16+
01.15 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» (S) 16+

### ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
11.50 «Понять. Простить» 16+
12.50 «Порча». «Пробуждение» 16+
13.20 «Знахарка» 16+
13.55 «Верну любимого» 16+
14.30 «ОБМАНУТЫЕ НАДЕЖДЫ» 16+
18.45 «Про здоровье» 16+
19.00 «ПОЧТИ ВСЯ ПРАВДА» 16+
22.45 «Порча». «Лужа». «Только вдвоём» 16+
23.45 «Знахарка» 16+
00.20 «Верну любимого» 16+
00.45 «Понять. Простить» 16+
01.35 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.25 «Тест на отцовство» 16+
04.05 «Давай разведёмся!» 16+
04.55 «6 кадров» 16+

### ЗВЕЗДА

05.20 «СЕРДЦЕ КАПИТАНА НЕМОВА». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ВОЗВРАЩЕНИЕ РЕЗИДЕНТА» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25, 15.05 «СМЕРШ. ДОРОГА ОГНЯ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Предвидение космоса». Документальный сериал. «Космическая дорога». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Мост через Амударью. Тайна ввода советских войск в Афганистан» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной. 12+
00.45 «НОЧНОЙ ПАТРУЛЬ» 12+
02.20 «СЫН ЗА ОТЦА…» 16+
03.40 «Сделано в СССР». Документальный сериал 12+

# ЙОЛДЫЗНАМӘ 7–13 НОЯБРЬ

**КУЧКАР (21.03 – 20.04)**
Бер мәсьәләдә үз хокукыгызны ныклап якларга туры килер. Борчыласы юк: барысы да сезнеңчә килеп чыгар. Шәхси тормышыгызга сәеррәк яңалыклар үтеп керер.

**ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)**
Атна башында мөмкинлекләрегезнең чамалырак булачагын истә тотыгыз. Юкса, булдырам, дип тотынган эшегез барып чыкмаска, кәефегез төшәргә мөмкин. Акчага бәйле шәп кенә хәбәрләр ишетерсез.

**ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)**
Дөньясы тынгысыз булган бер мәлдә күңелегезгә тынычлык иңдерердәй яңалыклар килеп ирешер. Атна уртасында рәхәт кешеләр белән аралашудан файда көтегез. Акчалы эш тәкъдим итәргә мөмкиннәр.

**КЫСЛА (22.06 – 22.07)**
Һөнәри осталыкны үстерү планнары белән янып йөри башлаячаксыз. Сәбәбе бик саллы… Керем мәсьәләсендә яхшы хәбәр (баю дисәк тә була) көтегез. Күптәннән башлап ташланган бер эшне тиз генә башкарып, әйбәт кенә файдасын күрерсез.

**АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)**
Бер эшегезнең нәтиҗәсе күңелегезне төшерер. Тырыштыгыз-тырыштыгыз да, бөтен әҗер-даны дигәндәй, башкаларга эләгер шикелле… Әмма моны сабак итеп кабул итегез. Озакламый рухи һәм хәтта матди канәгатьлек хисе алачаксыз!

**КЫЗ (24.08 – 22.09)**
Атна башында алдыгызга яңа офыклар ачардай хәлнең килеп чыгасын көтегез. Дус-ишләрегез арасыннан берсе куанычы белән уртаклашып шалтыратыр һәм сәеррәк кенә серен дә ачып салыр. Бу күңелегездә ниндидер бер шиккә урын калдырыр.

**ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)**
Күңел түрендәге хыялларыгыз чынга аша башлар. Күптәнге бер танышыгыз белән очрашып сөйләшү моңарчы сез белми йөргән кайбер әйберләргә төшенергә ярдәм итәр. Атнаның икенче яртысында җитәкчегезгә сәләтле кеше булуыгызны расларга туры килер.

**ЧАЯН (24.10 – 22.11)**
Бәйрәмнән соң ялкауланып киткән кебек булырсыз. Ләкин эшегездәге киеренкелек үзегезне бик тиз «форма»га кертер. Сөенеч: табыш артыннан кумасагыз да, ул үзегезне куып тотар!

**УКЧЫ (23.11 – 21.12)**
Авызыгызны белеп ачыгыз: һәрбер сүзегезне бизмәнгә салып үлчәүчеләр пәйда булырга мөмкин. Сәбәбе – уңышларыгыздан көнләшү. Атна уртасында телефон аша әйбәт хәбәрләр килеп ирешер.

**КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)**
Эштә күпләрдән бер башка өстенрәк торуыгызны раслардай мөмкинлек килеп чыгар. Ләкин борын чөя күрмәгез: уңайсыз хәлдә калуыгыз һәм моның тормышыгызда тискәре чагылыш табуы бар.

**СУКОЯР (21.01 – 19.02)**
Үз фикерегезне яклап, кемнәр беләндер сүзгә керергә мөмкинсез. Ләкин куркасы юк: хаклы икәнлегегез инде бик тиздән күренәчәк. Керемегезне арттырачак мөмкинлекләр пәйда булыр.

**БАЛЫК (20.02 – 20.03)**
Ниятләгәннәрне тормышка ашыру өчен искиткеч уңайлы чор. Тик менә гаиләдә фикерегез белән исәпләшергә теләмәү генә ачуыгызны чыгарыр.

# КАЙНАМЫЙ, КИСӘТӘ

**Сару кайнау – һәркайсыбызга яхшы таныш халәт. Күкрәк читлеге кызып тора, күңел болгана, тамакка әче су килә... Әнә шундый билгеләр белән азаплый ул. Аларга әллә ни игътибар бирмичә, кул астындагы чаралар ярдәмендә генә җиңәргә тырышабыз. Белгечләр исә, сару кайнау җитди авыру билгесе дә булырга мөмкин, дип кисәтә.**

**Табиб-гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА шул хакта тәфсилләбрәк сөйләде.**

**:: Ни сәбәпле сару кайный?**
– Сару кайнау ашказаны согы һәм кислотасы тәэсирендә үңәчнең лайлалы тышчасы ялкынсынганда барлыкка килә. Мондый хәл ашказанындагы әче сыеклык үңәчкә килеп эләккәч күзәтелә. Еш кына күп итеп ашаганнан соң һәм ятып торгач борчый ул. Сару кайнау ашкайнату системасы белән бәйле авыруларның бер билгесе булып торырга да бик мөмкин.

**:: Бу очракта нинди авырулар турында сүз бара?**
– Сару кайнау иң беренче чиратта гастрит, язва кебек авыруларның билгесе булырга мөмкин. Ул ашкайнату системасы әгъзалары эшчәнлеге бозылу (ГЭРБ) турында да кисәтергә мөмкин. Ашказанында бүсер булган, үт куыгы ялкынсынган (холецистит) кеше дә сару кайнаудан интегә.

**:: Сару кайнау күпкә китсә, чаң сугарга кирәк, димәк?**
– Әллә нигә бер генә күзәтелә икән, борчылырга кирәкми. Еш кына артыгын ашап ташлаганда сиздерә ул. Әмма сару бик еш кайный һәм даими рәвештә кабатлана икән, табибка күренергә кирәк. Сару кайнаганда ютәл, хәлсезлек, аппетит югалу, күңел болгану, тир бүленеп чыгу кебек билгеләр күзәтелсә, күкрәк турысында авырту сизелсә, аеруча игътибарлы булырга кирәк.

**:: Сару кайнауны күпләр сода ярдәмендә баса. Болай эшләү дөресме?**

САРУ КАЙНАГАНДА НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

| Ярый | Ярамый |
| --- | --- |
| алма, банан; | помидор, торма, редис, цитрус җимешләр, кузгалак, башлы суган; |
| бәрәңге (кыздырылган түгел), брокколи, кишер, кузаклылар; | туңдырма, сыр; |
| майсыз сыер һәм тавык ите, чиле-пешле йомырка яки тәбә, балык; | кондитер эшләнмәләре, шоколад; |
| майсыз сыр, каймак, эремчек; | майлы, ысланган, тәмләткечле ризыклар; |
| дөге, солы боткасы, искергән ипи; | сөтле коктейль, каһвә, цитрус җимешләр һәм мүк җиләге согы, |
| чәй, сөтле какао, газсыз су, алма согы | газлы эчемлекләр, шәраб, сыра |

– Андый чакта сода, дөрестән дә, хәлне җиңеләйтә. Әмма бу – вакытлы күренеш. Ул чирне дәваламый. Өстәвенә сару кайнаганда сода белән артык мавыгырга да ярамый. Ник дигәндә, ул ашказаны кислотасы белән реакциягә кергәндә, күп күләмдә углекислый газ бүленеп чыга һәм ашказаны сузыла. Бу исә тагын кислота бүленүгә китерә. Шул рәвешле кешенең хәле тагын да мөшкелләнергә мөмкин.

**:: Бу халәт – булачак әниләрнең дә аерылгысыз юлдашы бит...**
– Йөкле чакта карындагы бала барлык эчке әгъзаларны, шул исәптән ашкайнату органнарын да баса башлый. Өстәвенә бу чорда прогестерон гормоны ашказаны белән үңәч арасындагы мускулларны кыса. Шуңа күрә булачак әниләр йөклелекнең соңгы чорында гадәттә сару кайнаудан интегә.

**:: Халык медицинасы чаралары ярдәмендә генә котылып буламы?**
– Сару кайнауны дәвалый башлаганчы иң элек аның ни сәбәпле пәйда булуын ачыкларга кирәк. Әгәр ул чамадан тыш ашау арқасында барлыкка килгән икән, туклану рәвешен үзгәртергә. Әгәр ул ашкайнату системасы авыруларының бер билгесе икән, табиб билгеләгән даруларны эчәсе булачак. Диета сакларга да туры килергә мөмкин. Сару кайнаганда сөт, бәрәңге, бөтнекнең файдасын күрүчеләр дә бар. Әмма алар да хәлне вакытлыча гына җиңеләйтеп тора.

**:: Сару кайнауны кисәтү өчен берничә киңәш тә биреп китегезче.**
– Ризыкны аз-азлап һәм яхшылап чәйнәп ашагыз. Кыздырган, майлы, борычлы ризыклар белән артык мавыкмагыз. Шоколад, газлы су һәм каһвәне дә чикләсәгез яхшы булыр. Гәүдә авырлыгын контрольдә тоту да мөһим. Елга бер мәртәбә булса да, гастроэнтерологка күренеп, ФГДС үтү дә комачауламас.

## Ковид баш миен кечерәйтә?!

Галимнәр коронавирусның баш мие төзелешендә үзгәрешләр китереп чыгаруын ачыклаган. Алар чирне авыр формада уздыручыларда гына түгел, ковидны ис сизмәү кебек җиңелчә билгеләр белән аягөсте генә үткәргән кешеләрдә дә күзәтелә икән. 51–81 яшьлек 785 кеше арасында тикшерену уздыргач, галимнәр түбәндәге нәтиҗәгә килгән.

– Әгәр сез ковид белән авырганда ис сизми башлагансыз икән, димәк баш миенең нәкъ менә шушы эш өчен җавап бирә торган өлеше кечерәйгән, – ди галимнәр. Баш миенең шушы зонасында соры матдәнең дә азаюын ачыклаган алар. Шунда ук баш мие тукымасын зарарлаучы ялкынсыну билгеләре дә күзәтелгән.

Коронавирус белән авырып терелгән кешенең баш мие кечерәя! Галимнәр ясаган икенче ачыш шуннан гыйбарәт. «Дөрес, яшь барган саен баш миенең соры матдәсе болай да кими бара. Әмма ковид бу процессны тагын да тизләтә», – ди алар.

«Cell Reports Medicine» басмасы күптән түгел галимнәрнең тагын бер тикшерену нәтиҗәләрен бастырган. 450 кеше арасында тикшерену уздырып, алар коронавирустан соң кешенең авыр мәсьәләләрне хәл итү сәләте начарлануын, аның телдән әйтелгән мәгълүматны авырдан кабул итүен, мантыйк ягы аксавын ачыклаган.

### Истә тот!

Көтмәгәндә генә йөрәк кага башласа, түбәндәге күнегү ярдәмгә киләчәк. Моның өчен 5–8 секунд эчендә сулыш алырга, аны 3–5 секунд тотып торырга, аннары 5–8 секунд дәвамында акрын гына сулышны чыгарырга кирәк. Икенче тапкыр эшләгәндә ким дигәндә 3 мәртәбә түбәндәгечә кабатларга кирәк: 4кә кадәр санап суларга, 7гә кадәр санап, сулышны тотып торырга һәм 8гә кадәр санап, сулышны чыгарырга.

Саклап куй!

## ИММУНИТЕТНЫ НЫГЫТАБЫЗ

**МҮК ҖИЛӘГЕ ФАЙДАСЫ**
500 г мүк җиләгенә 2–3 яшел алманы кабыгы белән турап салырга да 1 стакан вакланган әстерхан чикләвеге, 500 грамм шикәр комы, 0,5 стакан су өстәп, сүрән утта кайнатып чыгарырга. Катнашманы банкаларга тутырып куярга кирәк. Әлеге катнашманы көн саен иртән һәм кич берәр аш кашыгы кабып куясы.

**ЛИМОН СИХӘТЕ**
Баш авыртканда лимон согы белән компресс куярга мөмкин. Көн саен бер лимон ашасагыз, югары кан басымын 10 процентка төшереп була. Бит шешенгәндә, лимон телеме белән сөртсәң, тиренең тонусы яхшыра. Тырнакка көн саен лимон телеме белән массаж ясасаң, тырнаклар ялтырап торачак, сынмаячак. Җил киптергән бит һәм кулга лимон согына йомырка агы туглап кушылган битлек сөртү файдалы.

**ЮКӘ ЧӘЕ**
Шикәр чиреннән интегүчеләр кандагы шикәр микъдарын киметә ала. Моның өчен 3 литр суга 2 стакан юкә чәчәге салып, 10 минут кайнатасы, суынгач, сөзеп, шуны суыткычта саклыйсы. Чәй урынына яртышар стакан эчәргә кирәк. Әзерләнгән төнәтмә беткәч, 3 атна ял итәсе, аннары дәвалау курсын яңадан кабатлыйсы.

**ЗОБТАН ФЕЙХОА**
1 килограмм фейхоаны иттарткыч аша чыгарырга. Шуңа 1 килограмм шикәр комы яисә 700 грамм бал кушып болгатырга кирәк. Банкага тутырып, берничә көн тотасы. Бу катнашманы иртән һәм кич берәр аш кашыгы ашарга кирәк. 10 көннән соң 10 көн тәнәфес ясагач, дәвалау курсын тагын бер тапкыр кабатларга мөмкин. Шул рәвешле 1 ай дәваланасы.

**СОЛЫЛЫ СӨТ**
1 литр сөткә 1 стакан солы салып кайнатып чыгарырга. Шуны бик сүрән утта 40 минут пешергәч, сөзеп, ашарга ярты сәгать кала җылы килеш яртышар стакан эчәргә кирәк. 1–2 ай буе шундый солылы сөт эчсәң, ашказаны җәрәхәте төзәлә, авырту басыла. Көн саен яңаны әзерләү яхшы, кичтән калганын җылыту файдасыз.

**ШИКӘР ЧИРЕННӘН – КАРЛЫГАН ЯФРАГЫ**
Кара карлыган яфракларын чәй кебек пешереп, озак вакыт эчсәң, шикәр чирен җиңәргә мөмкин. Бу чәйне ясау өчен 2 чәй кашыгы яфракны фарфор чәйнектә 10 минут пешерергә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

# КАБАК ИРЛӘРГӘ ФАЙДАЛЫ

**Кәҗә мал түгел, дигән кебек, кабакка карата да әллә нинди кадерсез мөнәсәбәт яши бездә. Буш урынга чүп үсмәсенгә генә утыртылган талымсыз яшелчәнең кадерен белеп бетермибез. Ә менә үләнче Фирая ЗАХАРОВА киңәшләре кабакка мөнәсәбәтне үзгәртә.**

vk.com

**:: Фирая ханым, кабакны витамины язга кадәр дә кимеми торган яшелчәләрнең берсе, диләр. Бу чыннан да шулаймы?**
– Әйе, тиешле шартларда саклаганда, кабакны көздән яз уртасына кадәр кулланырга була. Ул – витамины иң озак саклана торган яшелчә. Әлбәттә, аны чи килеш тә, пешереп тә, маринадлап та, тозлап, киптереп тә, маен һәм согын сыгып та кулланырга мөмкин.

**:: Кабак – антидепрессантмыни?**
– Кабак – игътибар итсәгез, шундый матур яшелчә бит. Төсе дә кәефне күтәрә торган. Ә сез әйткән үзлегенә килгәндә, ул, чыннан да, нерв системасы өчен җавап бирә торган В төркеме витаминнарына ($B_1$, $B_2$, $B_6$) бай. Гадәттә көз көне кеше болай да күңел төшенкелегеннән интегә. Ә быелгы вазгыять беркемне дә читләтеп узмады, шунлыктан стресстан, депрессия, күңел төшенкелегеннән газап чигүчеләр саны артты гына. Кул астында булган кабакны ашау беркемгә дә зыянга булмас. Ул нерв системасын ныгыта, тынычландыра, кәефне күтәрә.

**:: Күп кеше кабакны яратмый бит. Төче – балласаң да, тозласаң да күңелгә ятып бетми, диләр.**
– Әлбәттә, күп кеше яратмый, әмма яратырга кирәк! Иренмәсәң, аннан әллә нинди затлы ризыклар да әзерләргә була. Кабакта организм өчен кирәкле бета-каротин бар. Кабак согында ул, кишердәгегә караганда, биш тапкыр күбрәк. Ләкин һәр нәрсәнең чамасы бар. Бета-каротин күп дип, кабак суы гына эчәргә киңәш итмәс идем, чөнки бавырга кыен булуы бар. Шунлыктан яңа сыгылган кабак согы эчкәндә, аны 1:1 су яки 1:1 кишер согы белән бутап эчү әйбәтрәк. Кабак согы эчкән вакытта Д витамины яхшырак үзләштерелә. Бу бигрәк тә сөякләр белән проблемалары булган өлкәннәргә файдалы. Кабакта артык авырлыктан интегүчеләрдә май алмашын көйли торган Т витамины бар. Ул шулай ук аксым – углевод, су – тоз алмашын яхшырта.

**:: Пешереп ашасаң, файдасы азрактыр бит?**
– Кабак, мәсәлән, боткага салып пешереп ашаганда, углеводлы ризык буларак кабул ителә. Әгәр аны чи килеш угычтан уып, салатларга яки боткага кушканда, чыннан да, файдасы күбрәк. Болай кулланганда ул матдәләр алмашын яхшырта, иммун системасын ныгыта. Бик күп булмаганда бавыр белән бөергә файдасы бар, ул шулай ук кан басымын төшерә. Бөерендә таш булган кешеләргә һәм гипотониклар көн саен ашарга киңәш ителми.

**:: Кабакның йомшагы файдалыракмы, әллә төшеме?**
– Икесе дә файдалы. Кабак төшенең бигрәк тә ир-атларга һәм балаларга файдасы зур. Бу – хатын-кызлар ашамасын дигән сүз түгел, әлбәттә. Ул ир-атларны җенси проблемалардан, авырулардан саклый, дәртен арттыра. Кабакта шулай ук кукурбитин бар, ул организмдагы паразит суалчаннарны чыгара. Шунлыктан балаларда еш очрый торган бабасырдан котылу чарасы да ул. Кабакта эчәклек микрофлорасын көйләүче матдәләр дә бар. Шуңа күрә антибиотиклар эчкәннән соң да аны куллану файдага булыр.

**:: Кабак төшен куллануга килгәндә, шулай ук чамасын белергә кирәктер?**
– Атнага бер тапкыр, мәсәлән, ял көнне кич белән бер уч кабак төше ашауны гадәткә кертсәгез, бик яхшы. Йә булмаса көненә 10 данә ашап куйсагыз да файдасын сизәрсез. Төшләрнең кибеттә сатыла торган кипкәненә түгел, ә ачкач ук кулланганында витаминнар күбрәк. Кальций белән калий да күп.

**:: Укучыларыбызга берәр файдалы рецепт әйтсәгез иде.**
– Яңа ачылган кабакның 1 стакан төшен кабыгы белән блендерда изәргә һәм ярты стакан бал белән болгатып, шарчык итеп әвәләп, суыткычка куярга. Бик тәмле һәм файдалы шарчыкларны көненә берне ашарга киңәш итәм.

## Хуҗабикәгә

✓ Плитәдәге май табына тоз сибеп куегыз. Бераздан чистарту җиңелрәк булачак.
✓ Чәчәк вазасындагы суны түккәннән соң калган эзне бетерү өчен, вазага җылы су белән серкә салып тору да җитә.
✓ Табадагы балык исе бетсен дисәгез, аны башта җылы тоз белән сөртеп, аннары чайкап алыгыз.
✓ Суган белән сарымсак тураганнан соң исен бетерү өчен, кулны серкәле җылы суда юыгыз һәм чиста су белән чайкагыз.
✓ Йомшак ипине беразга суыткычка тыгып алсагыз, ул җайлырак киселәчәк.
✓ Ипи савытына бераз тоз куйсагыз, ипи тиз генә күгәрмәс.

## Тест

# ЙОКЫҢ ТУЯМЫ?




**1. Сезгә йокыдан уяну өчен будильник кирәкме?**
**2. Көндез хәл кертсен өчен, кофе яки энергетик эчәсезме?**
**3. Йокларга ятуга, 5 минут эчендә йоклап китәсезме?**
Беренче ике сорауга «әйе» һәм соңгысына «юк» дип җавап биргәнсез икән, димәк, сезгә йокы сәгатегезне арттырырга кирәк.

ЙОКЫНЫҢ ИҢ ФАЙДАЛЫ СӘГАТЬЛӘРЕН АЧЫКЛАГАННАР

| Тәүлек вакыты | 1 сәгате күпмегә тиң? |
|---|---|
| 19дан 20гә кадәр | 7 сәгать |
| 20дән 21гә кадәр | 6 сәгать |
| 21дән 22гә кадәр | 5 сәгать |
| 22дән 23кә кадәр | 4 сәгать |
| 23тән 24кә кадәр | 3 сәгать |
| 0дән 1гә кадәр | 2 сәгать |
| 1дән 2гә кадәр | 1 сәгать |
| 2дән 3кә кадәр | 30 минут |
| 3тән 4кә кадәр | 15 минут |
| 4тән 5кә кадәр | 7 минут |
| 5тән 6га кадәр | 1 минут |

## Тәмле булсын!

# АТ ИТЕННӘН КАЗЫЛЫК ҺӘМ ТУТЫРМА

**Рәмзия ГАТИНА рецепты**
– Ат суйган көнне үк, 3–4 сәгать үткәннән соң, итне вак кисәкләргә турыйбыз. Аңа тоз һәм үзеңә нинди тәмдә кирәк, шул чамадан чыгып, борыч, изелгән сарымсак салып болгатабыз. Итка тәмләткечләр сеңсен өчен, 5 сәгать тотабыз да, кабат болгатып, алдан яхшы итеп чистартып юылган 40–45 см чамасы озынлыктагы ат эчәгенә тутырабыз, ике башын да ныклап бәйләп куябыз. Соңыннан берничә урыннан энә белән тишекләр тишеп, кайнап торган суга 15 минутка салабыз. Аннары чормага элеп куябыз. Язга бик тәмле казылык хасил була. Ат итен тиз арада кулланмасаң, ачый, тәме үзгәрә. Ә болай эшләгәндә беренчел тәме саклана.

Малның эчке әгъзаларыннан тутырма ясап куям. Йөрәк, бавыр, үпкә, бераз ит салып, барысын бергә пешереп, иттарткычтан чыгарам, шуңа тоз-борыч кушып болгатам. Алдан бүрттерелгән ярма өстим. Дөге, тары, карабодай – кайсы да ярый. Шуларны 20–30 см озынлыктагы эчәкләргә тутырып, берничә җирдән энә белән тишеп, кайнаган суда пешерәм. Суынгач, туңдыргычка тутырып куям.

Мондый тутырма өчен сыер эчәге дә бара.

## Укучы киңәше

# КАЗ МЕНДӘРЕ ЯСЫЙБЫЗ

Бәйрәмнәрдә каз өмәләре башлана. Мамыкларын вакытында юып, мендәр өчен әзерләп кую турында да онытмаска кирәк, чөнки озак торган пычрак мамык исләнә.

Өмә узып берничә көн узуга, берничә көнемне мендәр өчен мамык әзерләүгә багышлыйм. Мамыкларны җылы суда шампунь белән юам, яхшылап җылымса суда чайкыйм һәм җылы мунча ләүкәсенә җәеп киптерәм. Яхшылап кипкәннән соң, юкарып беткән иске мендәр тышларына тутырып куям. Мамык «сугарга» тиеш, шунлыктан тыгыз итеп тутырмыйм. Аны бер ел яң иттергәннән соң гына мендәр итеп ясыйм.

Каз мамыгын шулай ук кер юу машинасында да юарга була. Мин бу ысулны гадәттә, иске мендәрләрне чистартканда кулланам. Юганда кер порошогы түгел, шулай ук шампунь куллансагыз яхшы.

*Зөлфия ДӘҮЛӘТШИНА.*
Мамадыш

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

# СЫНМАСЫН, СЫГЫЛМАСЫН

**Көч-куәт, батырлык кына түгел, сабырлык та сынала торган көннәрдә яшибез. Яхшыга өметләнәсе, ышанасы килә дә бит. Әмма кайчак сабыр канатлары да сынып куя шул. Мондый шартларда үз-үзеңне ничек кулда тотарга? Күңел төшенкелегенә бирелмәс өчен, нәрсәләрне белергә?**

**Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр эшчәнлеге буенча урынбасары Равил хәзрәт ЗӘФӘРОВ шул сорауларыбызга ачыклык кертте.**

**:: Бүгенге вазгыятьтә күңел ныклыгын саклау бик кыен. Якыннарын махсус операциягә озатучылар арасында депрессиягә бирелүчеләр дә шактый. Мондый шартларда ничек сынмаска-сыгылмаска? Күңел төшенкелегенә бирелүдән ничек сакланырга?**

– Тормыш булгач, төрле хәлләр була. Раббыбыз Аллаһ Коръәни Кәримдә дә: «Әлбәттә кыенлык, мәшәкатьләре бәндәләребезгә бирермен», – ди. Ягъни якыннарын, мал-мөлкәтен, сәламәтлеген югалтып, адәм баласы бу дөньяда төрле кыенлык-мәшәкать, хәсрәтләр күрә. Әмма андый чакта сабырлык кирәк. Үзенә тәвәккәл кылган колларын Раббыбыз ярдәменнән ташламас. Вазгыять төрле булырга мөмкин. Аңа карата безнең җавабыбыз нинди булырга тиеш? Әлбәттә, Раббыбыз Аллаһы Тәгалә кушканча. Бүген бик зур сынау чоры кичерәбез. Якыныңны югалту, кадерле кешеләрең белән озак вакытка саубуллашып тору, якыныңның гаиләне калдырып шундый зур, җаваплы сәфәргә китеп баруы зур сынау булып тора. Төшенкелеккә бирелүдән бернинди файда юк. «Язмышыма шулай язылган, шул хәлләрне, шул көннәрне күрергә насыйп булган икән», – дип, Раббыбыз Аллаһның барлыгын-берлеген онытмаска тиешбез. Бу шартларда сынмас-сыгылмас өчен, бердәнбер чара – Аллаһы Тәгаләне һәрдаим искә алу, аңа тәвәккәл кылу, аның хикмәтле, мәрхәмәтле икәненә таяну, күркәм исемнәрен телгә алу. Ерак сәфәргә китеп барган якыннарыбыз сау-сәламәт, җиңү белән кайтсыннар, дип догага булу да бүген төп эшебез. Шунсыз бу халәттән котыла алмабыз. Раббыбыз Аллаһны искә алмаган, дин кушканча яшәмәгән, күңел тынычлыгын Аллаһы Тәгалә тыйган хәмер кебек әйберләрдән эзләгән кеше юкка чыгачак. Раббыбыз колларын беркайчан ташламый. Коръәни Кәримдә дә: «Авырлык арты җиңеллек килер», – диелгән.

**:: Сабыр булу өчен нинди дога укырга?**

– Сабыр булу – бик зур нигъмәт. Раббыбыз Аллаһ «Гыймран» сүрәсендә: «Әй, моңлы бәндәләрем, авырлыкларга, дөнья мәшәкатьләренә, һәр төрле бәла-казаларга, дошманнарга сабыр итегез, Раббыбыз Аллаһтан куркыгыз, шаять ки өстен килерсез», – ди. Шуңа күрә сабырлык – Аллаһы Тәгаләнең олы бүләге. Аның рәхмәтенә, нигъмәтенә алып барган нәрсә – хәерле гамәл. Хәдисләрдә сабырлык турында бик күп сөйләнелә. Аллаһыбыз – рәхмәт, мәрхәмәт иясе. Әгәр Раббыбыз колы, куллары күтәреп, Аңа ялвара, сәламәтлек, иминлек, сабырлык, нигъмәт сорый икән, Аллаһы Тәгалә бу догага җавап бирә.

> Гарәп телендәге догаларны белмәсәк тә, үзебезнең ана телебездә: «Раббым Аллаһ, күркәм сабырлыклар бир. Бу мәшәкатьләрдә, кыенлыкларда динемә, сәламәтлегемә, тормышыма, хаятемә иминлек килсен, ошбу хәсрәтле хәлләр узып китсен», – дип ялварабыз икән, Аллаһы Тәгалә җиңеллеген бирә. Шуңа намазларыбыз, сәҗдәләребез, Коръән аятьләре укуларыбыз сабырлыкка алып бара, безне Раббыбыз Аллаһ белән бәйли. Ул безгә шул рәвешле күңел ныклыгы, күңел тынычлыгы сала.

**:: Сабыр кеше кыямәт көнендә хисап тотмый, җәннәткә әлегә дигән фикер яши. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?**

– Аллаһы Тәгалә: «Сабырларның саваплары чиксез булыр», – ди. Ягъни сабыр иткән адәм баласы чиксез савап-хәсәнәтләр белән бүләкләнә, Раббыбызның рәхмәтенә ирешә. Ул гына да түгел, дөньялыкта күп сабырлыклар күрсәткән, нинди генә хәл булса да, Аллаһка тел-теш тидермәгән, аңа тәвәккәл кылган кешегә кыямәт көнендә, әлбәттә, олы җиңеллекләр килә. Пәйгамбәребез дә тормышында бик күп кыенлык, мәшәкатьләр күргән. Үзе исән чакта алты баласын җир куенына сала ул. Башка төрле кыенлык, хәсрәтләр дә килә аңа. Әмма пәйгамбәребез сабырлардан булды. Хәтта улы Ибраһимны җирләгәннән соң да аның күзендә яшьләр күргәч, халык: «Син елыйсыңмы?» – дип сораган. «Әйе, күзләребезгә яшь килә. Күңелләребездә – сыкрау. Әмма ләкин телләребез хәерлене генә сөйли», – дип җавап биргән ул. Пәйгамбәребез үзенең күркәм үрнәге белән ничек сабыр булырга кирәклеген өйрәтте. «Чынлыкта сабырлык шулдыр: ул – авырлыкның иң беренче мизгелендә сабыр итү», – дигән. Аллаһы Тәгалә сабыр колларын сөя, якын итә, аларны рәхмәтеннән ташламый.

**:: Дин күзлегеннән караганда, күңел төшенкелегенә бирелү – гөнаһмы?**

– Кеше күңел төшенкелегенә бирелә, аның тормышы бөтенләй туктала, Аллаһ Раббыбызның әмерләренә колак салмый башлый, гомеренә кул селти икән, болар – әлбәттә, гөнаһлы гамәлләр. Бу – кешене һәлакәткә алып бара торган нәрсә. Аллаһы Тәгалә: «Үзегезне үзегез һәлак итмәгез», – ди. Кешенең шул дәрәҗәгә җитүе аны чиргә сабыштыра, җәмгыятьтән, гаиләсеннән аера. Бу инде тагын да зуррак бәлагә алып бара. Шул сәбәпле кеше, үзенә йомылып, бөтен дөньядан явызлык кына эзләп, үз-үзен битәрләп, үз-үзен һәлак итәргә дә мөмкин. Шуңа күрә бу – гөнаһ. Ул халәттән саклану кирәк.

**:: Сабырлыкның да чиге була бит. Андый чакта нишләргә?**

Кризис шартларында кече һәм урта эшмәкәрлек тармагында әйләнештәге капиталга ихтыяҗ туды. Эшмәкәрләр, заказны вакытында үтәү өчен, тиз генә вакыт эчендә материаллар һәм чимал сатып алырга мәҗбүр. Әлбәттә инде, мондый очракта алар кредит алу өчен банкка мөрәҗәгать итә. Әмма кредит алуның тиз генә башкарыла торган эш түгеллеген барыбыз да яхшы беләбез. Тиешле документларны җыеп тапшырып, кредитны хуплау-хупламаулары турында җавап алганчы шактый вакыт уза. Шуңа күрә бу эшне тизләтү өчен, яңа программа эшләдек. Дәүләт контрактлары буенча торгларда катнашучы оешмаларга эшләрен башкару өчен ярдәм тәкъдим итәбез. Бу максатка, гаризаны гадиләштерелгән нигездә карау юлы белән, контрактны үтәү өчен, 20 миллион сумга кадәр залогсыз кредит рәсмиләштерергә мөмкин. Шуның нәтиҗәсе буларак, зур сәүдә челтәрләренә товарлар тизрәк кайтарыла. Моннан тыш әйләнеш капиталы өчен 300 миллион сумга кадәр классик кредитлар да бирелә.

Соңгы вакытларда эшмәкәрләр арасында «Самоинкассация» программасы популярлашып китте. Клиентларыбыз, шуннан файдаланып, банкомат яки автоматлаштырылган депозит машинасы аша көндәлек керемнәрен үзләренең исәп-хисап счетына күчереп бара. Акча берничә минут эчендә үк счетта пәйда була.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

5 ноябрь көнне «СМП Банк» акционерлык җәмгыятенең идарә рәисе **Александр Анатольевич ЛЕВКОВСКИЙ**га 50 яшь тула. Хөрмәтле Александр Анатольевич! «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе безнең белән хезмәттәшлек итүегез, ышанычыгыз өчен рәхмәт белдереп, Сезне юбилеегыз белән тәбрик итә. Тормыш юлыгыз якты, сәламәтлегегез нык булсын! Гаилә бәхете телибез, якыннарыгызның ихтирамын һәм игътибарын тоеп яшәргә язсын! Изге теләк-ниятләрегез, якты уй-хыялларыгыз тормышка ашсын! Хезмәтегез һәрвакыт югары бәяләнсен! Тормышның һәр мизгеленә сөенеп яшәгез!

Олы хөрмәт белән, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективы

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүләре, Татарстан Республикасында милләтләр арасында татулыкны һәм тынычлыкны ныгытуга зур өлеш кертүләре өчен «Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе баш балетмейстеры **Гарипова** Раилә Мухаметхан кызы, Казан шәһәре Вахитов районының «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе директоры **Хухунашвили** Маринэ Мануиловна, «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Дәүләт халык уен кораллары оркестры сәнгать җитәкчесе һәм баш дирижеры **Шутиков** Анатолий Иванович **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**«Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыятенә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирү турында**

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәне, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән предприятие хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Татхимфармпрепараты» акционерлык җәмгыятенә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирергә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ ПУ-781

Сәрия МИФТАХОВА

# БЕЗ КҮРГӘН ҮРНӘК

**17 авылга – бер хуҗа. Арча районының Үрнәк авыл җирлеге башлыгы Васил Габделхаков әнә шуның кадәр авыл өчен җавап тота. Алар арасында Казанбаш, Үрнәк кебек зурлары, Дүртөйле, Тылаңгыр кебек бик кечкенәләре дә бар. Барысына да игътибар җитәме? «ВТ» хәбәрчесе җирлектәге халыкның яшәеше белән танышып кайтты.**

### Һәр авыл үзгә...

Җирлектә 3200дән артык кеше көн күрә. Әйтик, Үрнәк авылында 955 кеше исәпләнсә, Бимәргә җәен берничә кеше генә кайта. Башка вакытта монда – тынлык. Хикмәт санда түгел. Кечкенә авылда да зурысындагы кебек үк юлын, суын – барысын да карап торырга кирәк.

– Документта 15 авыл теркәлгән. Үрнәк белән Лесхоз – бер, Сурнар белән Казанка бер авыл санала. Ләкин бу – дүрт авыл дигән сүз. Шулай итеп, безнең җирлеккә 17 авыл керә. Иң ерак дигәне – 13 чакрым. Һәр авылның – үз холкы. Гаиләдәге балалар да бер-берсенә охшамый бит. Бездә күмәкләшеп эшлиләр, халык тырыш. Йортларда 5–6 сыер тотучылар күп. 15–20шәрне тотучылар да бар. Әнә җиденче дистәне ваклаучы Фирая һәм Рәис Галәвиевләр 25әр сыер асрый. Сөт ризыкларын авыл халкына һәм Казанга илтеп саталар, – ди әлеге вазыйфага ике ел элек билгеләнгән Васил Габделхаков. – Һәр авылның – үз мәшәкате. Читтәге авылларда проблема күбрәк. Һәрберсенең яшәргә хакы бар. Яшьләр күбрәк шәһәргә тартылса да, авылны яратучылар да аз түгел. Анда яшәүчеләргә шартлар тудырырга тырышабыз. 1–2 бала өчен мәктәп тотып булмас та инде. Тик клубы, бакчасы булсын. Ябылган ике бакчаны клуб һәм китапханә итеп үзгәрттек. Кечкенә авылларга да ял итү, аралашу өчен урын кирәк бит. Кайбер авылларда Сабан туйлары узмый башлаган иде, моны да хәл иттек.

Бу җирлектә берничә оешма эшли. Аларының да, дәресргә, җитәкчеләренең мөнәсәбәте төрле. Эшчеләренең көнкүреш тормышына битараф булганнары да юк түгел. Эшкә килсәләр, шул җитә, кыскасы. Тик кечкенә авыллар яшәсен, бетмәсен, дип тырышучылар да бар. Көтектән Дамир Шакирҗанов крестьян-фермер хуҗалыгы оештырып җибәргән. Авылда мәчет төзетүне үз өстенә алып, хәзер аны ачу мәшәкатьләре белән йөри. Казанбаштан Айдар Сабиров та, таралган трактор паркын, беткән терлекчелекне торгызып, авыл халкын эшле иткән. Күлтәс авылы халкы Илһам Шәяхмәтов җитәкчелегендә күлне чистарткан. Арча урман хуҗалыгы җитәкчесе Шамил Хәйруллин, Үрнәк агросәнәгать көллияте җитәкчесе Зөлфәт Дәүләтбаев та халык проблемаларыннан читтә калмый икән.

### Иң мөһиме – юл

Җирлек башлыгы өчен иң мөһиме – халыкны борчыган проблемаларны вакытында хәл итү. «Хәзер кеше безгә килеп тә тормый, гозерен телефоннан гына җиткерә. Элек авыл советына, колхоз идарәсенә яки районга барып җиткәнче ярсулары сүрелә иде, хәзер барысын да кызуында сугалар», – ди Васил Габделхаков.

Иң авырткан урын – юл мәсьәләсе. Кече Төрнәләдә, Тылаңгырда район ярдәме белән таш юл салганнар. Киләсе елга асфальтлы итү планга кертелгән, ләкин, барып чыгар микән, дип борчылалар. Дөньяда барган хәлләрне күреп торалар. Кечкенә авылларга район күләмендә автокибетләр китерү оештырылган.

– Узган ел 1 миллион сумнан артык үзара салым акчасы җыйдык. Бу сумма кечкенә авылларда кеше башына – 1 мең, башкаларында 300–500 сум. Зур авыллар рәхәтрәк яшәргә өйрәнгән. Аларның таләпләре күбрәк, әмма бирү ягы азрак. Хөкүмәттән күбрәк көтәләр. Кечкенә авылларда үзара салым акчасын җыю җайлырак, – ди җирлек башлыгы.

Үзара салым акчасының күпчелеге юллар өчен тотылган. Әйтик, быелтыр моның өчен 4 миллион сум акча киткән. Шулай ук чишмәләр, зират, юллар төзекләндерелгән, су гидрантлары, балалар мәйданчыклары булдырылган, капка төпләрендәге агачлар киселгән, зиратка кирәкле җиһазлар сатып алынган.

### Капкалар ачык булсын!

Без барып күргән Тылаңгыр авылында бүген 19лап йортта яшиләр. Элек клубы да, мәктәбе дә эшләгән. Эш булмагач, халкы кимегән. Авыл матур: якында гына урман, чишмәләр күп. Авыл халкы юл салдырган өчен район һәм авыл башлыкларына рәхмәтле.

– Бу авыл әллә ни артмый да, кимеми дә. Егерме биш чамасы йорт бар. Күбесендә өлкәннәр яши. Буш өйләр дә бар. Элек һәр йортта бала-чага, урам тулы халык булыр иде, – ди Нариман ага.

Сүзгә тормыш иптәше Фирдинә апа кушыла: «Безнең авылдагы кешеләр тәртипле. Ике күршедә таҗиклар гаиләсе яши. Телләрен белмәсәк тә, аралашып торабыз. Әле менә бәбиләре туды, аны күрергә чакырдылар. Тагын күчеп килүчеләр табылса, яхшы булыр иде, – ди ул. – Хәзер авылдашлар көндез дә капкаларын бикләп куя башлады. Элек шәһәргә барганда да ишекне бикләп йөрмәдек. Менә монысы – безнең өчен ят күренеш».

### Әби сүзе – закон

Үрнәк авылындагы дүрт буын бергә яшәгән Галимовлар гаиләсенә дә сугылдык. Бер йортта сигез кеше алар. Әшрәпбану әбигә – 95 яшь. Әле дә эшсез тормый: токмач җәя, камыр ризыкларын да пешерә. Иң яратканы – бәрәңге әрчү.

– Мин килгәндә, каенанам – пекарняда җыештыручы, каенатам кочегар иде. Дүрт бала тәрбияләгәннәр. Татулык булмаса, шуның кадәр яшәмәс идек. Ирем Фәрит белән гаилә коруыбызга – 44 ел. Олыларны хөрмәт иттек, кыек сүз әйтергә дә курка идек. Каенана картайгач, без хуҗа булдык, аннан киленем Эльмирага калыр. Менә шулай бара инде тормыш. Тик әбиебез сүзеннән чыкмыйбыз. Берберебезнең холкына ияләштек, берәребез каядыр китсә дә, юксына башлыйбыз, – ди Нурдания ханым.

Нурдания апа белән Фәрит абый өч бала үстергәннәр. Уллары Алмаз, киленнәре Эльмира, өч оныклары – алар янәшәсендә. Эльмира Мари Иленнән килен булып төшкән. Үзе дә – ишле гаиләдән, шуңа күрә дүрт буынның бергә яшәвенә бер дә аптырамый.

– Күңелле яшибез. Авырлыклар уза да китә. Өебездә тынычлык. Әлеге дуслыкның гомер буена саклануын телим. Үзем дә килен белән яшәр идем. Чыгып китәргә мөмкинлек бар иде, иремнең авылда каласы килде, мин сүзеннән чыкмадым. Әти-әнине тәрбияләргә кирәк, безне шулай өйрәттеләр, – ди Эльмира.

Алар яшәгән Подгорная урамындагылар бер-берсе белән дус. Сабан туен, Яңа ел бәйрәме, төрле ярышларны бергәләп үткәрәләр. Шашкасын да бергә уйныйлар. Урамның үз кубогы бар. Урамда гына түгел, җирлектә дә бер-берсенә ярдәм итеп яши халык. Мобилизация буенча киткән егетләрнең гаиләләренә дә бергәләшеп ярдәм иткәннәр. Үрнәктә үрнәк булмыйча ярамый.

Зөһрә САДЫЙКОВА

# БӘРӘКӘТЕ БУЛСЫН!

## АВЫЛЛАРДА ӨМӘ, СУГЫМ ЧОРЫ БАШЛАНА

**Әле кайчан гына урам, су буйларын тутырып йөргән каз тавышлары сирәгрәк тә, моңсурак та ишетелә бу көннәрдә. Шулай булмый ни, авыл халкының ел әйләнәсе тырышып, көч куеп үстергән маллары кулга керер чак җитте шул. Шуңа күрә авылларда мәшәкатьле дә, күңелле дә чор хәзер. Сугым, каз өмәләре гөрләгән вакытлар элек-электән туклык, муллык чоры булып саналган. Хәзер дә бәрәкәте белән кадерле. Республика районнарында өмәләр нинди рухта уза? Ит бәяләре ничек? Без шул хакта белештек.**

**Казлы тормыш – сыйлы тормыш**

Буа районының Ташкичү авылы халкы күпләп кош-корт, бигрәк тә казлар асравы белән данлыклы. Биредә аларны меңәр баш алып үстерүчеләр дә бар. Шуңа күрә бу көннәрдә авылдагы рухны чамалау кыен түгелдер. Әмирғалиев Ишегалды саен өмә гөрләгән көннәр. Әхмәдуллиннар быел 120 баш каз үстергән.

– Башкалар белән чагыштырганда, бу бик аз, – дип елмая гаилә башлыгы. – Күпләп асраучылар казларын бер атна тирәсе элек эшкәртә башлады инде. Без өмәне бу атна ахырына билгеләдек. Бер көндә эшен бетермәкче булабыз.

Салих Әхмәдуллин кош-корт белән беррәттән үгезләр дә асрый. Яшерми, аларын тәрбияләү мәшәкатьлерәк тә, чыгымлырак та.

– Без зур терлекләр дә тотабыз, тик каздан табыш күбрәк алабыз. Үзегез уйлап карагыз: бер айлык бәбкәне 350–400 сумга аласың икән, эч-башларын сатып, аның акчасын кире кайтарасың. Мин үзем урып-җыюда эшләгәч, ашлык белән авырлык юк. Үзебезнең дә пай җиребез бар. Иген сатып алган кешегә дә күп түгел ул. 200 казны 5 айда үстереп эшкәртеп тә куясың. Ә бер үгездән табыш алырга 1–1,5 ел вакыт кирәк. Бозауны 20–25 мең сумга сатып алып, тәрбияләп үстергәнче шактый чыгым, хезмәт таләп ителә. Кош-кортның мәшәкате дә азрак. Казның, тизәгеннән кала, бар нәрсәсе сатыла. Чегәннәр мамыгын да бер килосын 1000 сумнан алып китә. Ә үгез тиресенең бәясе гел юк. Маен да яратмыйлар, – дип исәп-хисапка бирелә Салих Әхмәдуллин.

**Зарланырлык түгел**

Кош асрауның төшемле эш булуына Мөслим районы фермеры Илназ Бәширов та инанган. Ул инде сигезенче ел кошчылык белән шөгыльләнә. Казлар, бройлерлар үстерә. Бүген Әмәкәй авылындагы фермаларында 5 мең баш каз асрый алар.

– Бу көннәрдә бик кызу «урак өсте» бездә, – диде Илназның хатыны Ралинә. – Казларыбыз күп булгач, шактый озакка сузыла ул безнең. Беренче казларны 1 ноябрьдә эшкәрттек, декабрь урталарына кадәр дәвам итәчәк әле. Күрше-тирә авылларда яшәүче апаларыбыз, әбиләребезгә рәхмәт инде. Алар бик нык булыша. Күмәк көч белән рәхәт итеп эшлиләр үзләре. 1 казны 150 сумнан йолкытабыз. Узган ел шушы эшләр өчен бар уңайлыклары булган цех төзедек. Апалар безнең сугым чоры башланганны көтеп торалар. Дөрес, 160 сумнан йолкытучы кешеләр дә бар. Ләкин аларда тиз чистарту җайланмалары юк.

Бәшировлар быел 60 мең бройлер да алган әле. Билгеле, аларын күптән суеп эшкәртергә өлгергәннәр инде. Болар өстенә яшь гаилә ат һәм тавык итеннән колбасалар җитештерә башлаган.

– 2015 елдан бирле шөгыльләнгәч, сату эше җайга салынды инде. Үзебезнең Мөслимдә сатабыз. Интернетта күреп тә килүчеләр бар. Элек катыргычларны кешедән арендага алып эшли торган идек. Быел цехта ике катыргычыбыз бар. Казларны болай да, ыслап та, каклап та сатабыз. Күпләп алган очракта, безнең якларда казның бер килосы 500 сумнан йөри. Берәмләп алганда – 550 сум. Казның эч-башларын 150 сумнан җибәрәбез. Фермерлар өчен яхшы хак бу, зарлана торган түгел.

Ралинә Бәширова әйтүенчә, каз биш айда яхшы булып өлгерә. Симерсен әле, дип озак ашатып тотуның мәгънәсе юк.

– Аны биш айдан да озак тотмыйбыз. Шулай иткәндә ите йомшак та, сусыл да була. Тиз дә пешә. Халык казның суйганнан соң катырылганын яратып ала. Ә менә Яңа ел алдыннан какланган һәм тозланган казлар күп сатыла. 2020 елда, пандемия вакытында, халыкның сатып алу мөмкинлеге кинәт төште. Аеруча бройлерлар сатканда сизелде бу. Түшкәсе белән сатылмагач, итләтә җибәреп карадык. Тик анысы да бармады. Шуннан соң беренче тапкыр тавык рулетлары ясадым. Менә анысы яхшы сатылды. Әзер ризыкка ихтыяҗ яхшы булгач, колбаса ясый башладык, – диде тырыш Ралинә.

**Ашарына булса гына...**

Хәер, соңгы елларда өмәләр бары тик суыклар төшкәч кенә башлана, дип әйтеп тә булмый. Мал эшкәртеп сатучы кешеләр ел дәвамында халыкны ит белән тәэмин итә, кош-кортларын да август – сентябрьдә үк ларга тутырып куючылар бар. Чүпрәле районының Иске Чокалы авылында яшәүче сугымчы Илдар Усманов та шулай ди.

– Бүген генә егетләр белән шул турыда сөйләштек. Без малай чагында 7 ноябрьләргә каз өмәләре башлана иде. Хәзер андый күренеш бетте бит. Халык зур ларлар алып куйды. Тели икән августта, тели икән, сентябрьдә эшкәртә кошларын. Зур мал чалу да шулай ук. Өмә дә ясап тормый гына, бер-ике туганы белән эшкәртә ул аны. Безнең тирәләрдә алгы бот – 400 сумнан, арткысы 450 сумнан йөри, – ди ул.

Аның сүзләренчә, соңгы ике-өч елда авылда мал тотучылар шактый кимегән. Аеруча узган ел, җәй коры килү сәбәпле, терлек азыгы юнәтү авыр булды. Фермада эшләүчеләргә дә каешларын кысыбрак буарга туры килә: закон катгый.

– Һәркайсын сатып ала башлагач, мал асрау үзен акламый. Табышын күргәнче, 1–1,5 ел үстерәсе, көн буе карыйсы бар бит әле аны. Күпләп мал асраучыларның кайсының – төп кәсебе шул, кайсы өйрәнелгән гадәт буенча, хәленнән килгәнчә тота, – ди Илдар Усманов.

### ИТ БӘЯЛӘРЕ

Казның бер килограммы – 500–550 сум
Эч-башларының килограммы – 350–400 сум
Үрдәкнең бер килограммы – 600 сум
Ысланган казның бер килограммы – 1000 сум
Какланган казның бер килограммы – 1300 сум
Эретелгән каз маеның 1 литры – 300 сум
Каз мамыгының бер килограммы – 1000 сум
Терлекнең алгы боты – 400–430 сум
Терлекнең арткы боты – 450–470 сум

## БЕЛГЕЧ ФИКЕРЕ

**Ралинә БӘШИРОВАдан каз асрау буенча киңәш:**

– Казларны 5 айдан да озаграк тотарга ярамый. Яшь кош мичтә дә тиз пешә, ите дә йомшак, сусыл була.

Казларга ашлыкны пешереп ашатучылар бар. Бу – хата. Каз алай үсә алмый. Мәсәлән, без тарттырылган бодайга жмых кушабыз. Бу казны симертә һәм тизрәк үстерә.

**Мал табибы Мөхәммәт ШӘРӘФИЕВтан терлек симертү буенча киңәш:**

– Әгәр хуҗалык үзенең пай җирендә клевер, люцерна үстереп, шуны алып кайтып ашата икән, көзге айларда малларга фураж да бирергә кирәкми. Аны бәрәңге беткәч кенә ашата башларга кирәк. Фураж ул сөтне дә артык арттырмый. Кеше организмына итне эшкәртү ничек авыр булса, сыерга да шулай ук. Шуңа күрә чөгендер үстерү отышлы дип саныйм. Тик шикәр чөгендерен сак кына бирергә кирәк. Күләмен арттырып җибәргәндә, мал эче китеп җәфаланырга мөмкин. Хәер, шикәр чөгендерендә генә түгел, чама хисен һәр нәрсәдә дә онытмаска кирәк. Бәрәңгене көненә – 12 литрлы чиләк белән ике тапкыр, ә чөгендерне 30 килодан да арттырмау яхшы. Ашлык, фуражга өстәп бәрәңге ашаткан мал яхшы була. Аны пешереп мөгезатлыларга дә кирәкми хәтта. Чи килеш тә файдасы зур. Гомумән алганда, симертергә куелган терлек тәүлегенә 1–1,5 килога кадәр артырга тиеш. Ә инде 1,5 яшьлек үгез 480–500 килограмм булса яхшы. Суясы малга силос ашатмау яклы мин, чөнки итендә ачы тәм була. Ә менә бәйдә торган, аз хәрәкәтләнгән, күбрәк ятып торган малның ите йомшак була, чөнки болай иткәндә аның мускуллары катмый, йомшак ите генә үсә. Су эчү дә бик мөһим. Терлек сусыл үлән ашаса, су кимрәк кирәк. Маллар өчен талык су 7–12 градус һәм чиста булырга тиеш. Мондый суны сыерлар яратып эчә.

## СЕЗДӘ ӨМӘЛӘР БАШЛАНДЫМЫ ӘЛЕ?

**Миләүшә МӘРДАНОВА, Лаеш районы Олы Елга авылы:**

*– Бездә кош-кортны да, терлекне дә аз асрыйлар. Шуңа күрә өмәләр гөрләп үтә, дип әйтеп булмый. Каз асраучы бернничә гаилә бар. Алар кошларны ноябрь ахырында туган-тумачалары белән җыелып эшкәртә. Мал-туарны да аяк асты катыргач, карлар төшкәч чалалар. Бездә сатуга дип үстерүчеләр күп түгел. Ит бәясе 430–450 сумнан йөри.*

**Гөлнур ФӘТХЕТДИНОВА, Чистай районы Исләй авылы:**

*– Бездә халык күпләп кош-корт, мал-туар тота. Өмәләр башланмады әле, беренчеләре бу атна ахырында булыр, дип көтәбез. Кешеләр үрдәкләрен генә эшкәртте. Олы терлекләрне исә, сатасы булгач, ел дәвамында суеп торалар.*

**Гөлүсә ГАБДРАХМАНОВА, Азнакай районы:**

*– Хәзер өмәнең билгеле бер вакыты юк. Кем кайчан өлгерә, шул вакытта тотына. Әлегә бездә үрдәкләрне симертәләр. Үзебез август – сентябрьдә эшкәртеп куйдык. Казларны ноябрь ахырында эшкәртербез дип уйлыйбыз. Берничә хатынкыз, чиратлашып, бер-беребезгә өмәгә йөрештек. Олы малга килгәндә, ит бәясе 450 сумнан йөри.*

## РАМИЛ МИНДИЯР:

# «ЗАКАЗ БУЕНЧА БЕРНӘРСӘ ДӘ ЭШЛӘМӘДЕМ»

**Туксанынчы елларда иң популяр җырчыларның берсе. Лирик җырлары белән дә, тарихи җырлары белән дә халык күңелен яулаган шәхес. Сүзебез – Рамил МИНДИЯР турында. Бүген ул нинди уй-фикерләр белән яши? Татар эстрадасына нинди бәя бирә? Без әнә шулар хакында сөйләштек.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

**:: Һәр елны беренче кар «Кышкы учак» җырына ияреп ява дисәк тә, хата булмас, Рамил абый. Нәкъ менә шушы җыр ничәмә-ничә буынга кадерле. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?**

– Бу җырны беренче карга яки кышкы сезонга бәйләп карарга, бәлки, ярамыйдыр да. Ник дигәндә, аны кайда гына чыгыш ясасам да сорыйлар. Җәен дә, көзен дә, язын да. Бу җыр «Әйдә барыйк, кызлар карыйк» (Разил Вәлиев) спектакленә махсус язылды. Аның көен Луиза Батыр-Болгари иҗат итте. Шушы спектакльдән соң кайда гына чыгыш ясасам да, әлеге җырны сорамый калганнары юк. Сүз белән көйнең тәңгәллегендә, кеше гомере турында тирән фәлсәфә ятуындадыр аның хикмәте. Мин һәрвакыт җырның сүзләренә игътибар итәм. Мәгънә бар икән, алынырга була. Мөгаен, мине танытыкан җыр шушыдыр. Спектакльләргә язылган күп җырларны башкардым. Әйтик, туксанынчы елларда Казанда Яшьләр театры Зәйни Шаһиморат пьесасы буенча спектакль чыгарды. Анда «Кайт, иркәм Сәрвиназ» җыры бар иде. Дөрес, ул бер куплетлы гына иде. Икенчесен үзем яздым. «Торналар» да шушы ук спектакль өчен махсус язылган. Шушы җырлар белән халыкка чыктым, дип әйтергә була. Ул чакта бит авылларга гастрольләргә йөреш бар иде. Халык еш кына «Сәрвиназ» килгән икән дип каршы алды. «Авылым тавышлары» кайткан, дип тә әйткәннәре булды. Аннан Миндияр булып киттем. Гәрчә ул – минем әткәйнең исеме. Багданов дигән фамилиям бөтенләй онытылды берзаман. Миндияр булып китүемә һич кенә дә үкенмим. Әткәйнең исемен мәңгеләштерүнең бер формасы лабаса бу.

**:: Моңлы кеше тыйнак була, диләр. Нәкъ сезнең хакта әйтелгән, ахрысы.**

– Артык тыйнак, диләр шул. Хәзерге заманда тыйнаклык бик килешеп тә бетми бугай инде. Нишлисең, Аллаһы Тәгалә шулай яраткан. Хәзер үзгәреп булмый инде. Мәрхүм апам, мәрхүм Расих абый, Рәсил абыем – алар кыюрак иде. Мин йомшаграк булганмын. Бәлки, моңга тартылгангадыр ул. Әнием Закирә бик чая, кыю татын иде. Сугыш елларында колхоз рәисе булган. Әти – ут. Ул башка кеше якын да килә алмаган айгырларны тәртә арасына кертә иде. Сугыштан соң әти дә колхоз җитәкләгән.

**:: Ә шундый тавыш иясе булып та, театр юлын сайлавыгызның сәбәбе нидә?**

– Балачактан җырчы булу турында хыялландым. Илһам Шакиров, Мәгафүр Хисматуллин, Фәридә Кудашева җырларын тыңлап, аларның репертуарын ятлап үстем. Мәктәптә укыганда, сәхнәдән төшми идем инде. Шуңа күрә мәктәпне тәмамлагач, Уфа сәнгать училищесына укырга кердем. Өченче курска җиткәч, хәрби хезмәткә киттем, флотта хезмәт иттем. Менә шуннан тавышымны югалтып кайттым. Мөгаен, суык, дымлы һава үз эшен эшләгәндер. Армиягә кадәр, сәнгать училищесында укыган чакта ук, профессор Фәрдүнә Касыймова: «Син – коеп куйган артист бит, театральныйга кер», – дип әйтә иде. Тора-бара ул миңа әнием кебек якын кешегә әйләнде. Аның юраганы юш килде, армиядән соң Уфа сәнгать институтына театр бүлегенә укырга кердем. Ә тавышны дәвалау һәм кире кайтару өчен күп вакыт һәм көч сарыф ителде. Бөтенләй үк кире кайтмаса да, тавышны дәваладым, дип әйтеп була. Һәрхәлдә Мәҗит Гафури исемендәге башкорт академия театрында җырлы рольләрне яратып башкардым. «Зәңгәр шәл»дә (Кәрим Тинчурин) , «Кызыл паша»да (Нәҗип Асанбаев), «Кара йөзләр»дә (Мәҗит Гафури) төп рольләрне уйнадым. Биш ел эшләгәннән соң театрдан китәргә туры килде.

**:: Китүнең сәбәбе – актер хезмәтенең тиешенчә бәяләнмәвеме?**

– Әгәр хезмәт хакын күз уңында тотсагыз, мин беркайчан да акча артыннан кумадым. Мөгаен, җүләрлек, кызу канлылык сәбәпче булгандыр. Юкса бит түзәргә кирәк. Һәм беркайчан да хәлиткеч карарларны кызган баштан кабул итмәскә кирәк. Миңа сабырлык җитмәде. Нәтиҗәдә яраткан эшемне, гаиләмне ташлап, шахтага чыгып киттем.

**:: Үкенәсезме?**

– Үкенүдән ни файда? Үткәннәрне үзгәртеп булмый бит. Иң үкенечлесе: кызым якты дөньядан бик иртә китеп барды.

...Аннары Казанга кайттым. Кемеровога гастрольгә казаннар килгән иде. Шунда очрашып, әйдә, Казанга, безнең үз төркемебез дә бар, диделәр. Чакыргач, кайттым. Ләкин ул егетләр каядыр югалды. Мин Яшьләр театрына барып кердем. Анда ике генә спектакльдә катнаштым. «Уеннан уймак» дигәне язмышымда хәлиткеч рольне уйнады, дип әйтсәк тә була. Андагы җырлар минем визит карточкама әйләнде.

**:: Хәзер театрга йөрисезме?**

– Йөргәләдем. Мине, сәхнәгә чыгасың икән, анда яшәргә кирәк, дип өйрәттеләр. Бу – театр сәхнәсенең дә, эстрада сәхнәсенең дә кануны, бер караганда. Җырлаганда шул җырда эреп бетмисең икән, ул бит тамашачыга «тими». Үзең ышанып эшләгәндә генә, халыкка фикерең барып җитә, үзең дә эшеңнән рәхәтлек кичерәсең. Хәзерге куелышларда бөтен нәрсә бар, яшәү җитеп бетми кебек. Белмим, миңа актерның «посыл»ы барып җитми инде. Шуннан соң театрга йөрисе килми башлый.

**:: Сез телевидениедә дә бик күренми идегез бит әле.**

– Мөгаен, телевидениедә кемгәдер ошамаганмындыр. Кайдан җил искәнен дә беләм инде. Уҗәтләнеп, ишек шакып йөргәнем булмады. Чакырган җирдән баш тартмадым. Иҗат активлыгына килгәндә, хәзер бит аренда хаклары бик кыйммәт. Бер-ике концерт белән генә сәхнә чыгымнарын каплап булмый. Белмим, нәрсә өчен шулай эшләнә бу? Сәнгатьне бетерү өчен дисәк тә, хата булмас.

> Тавышлы, моңлы җырчыларга сәхнәгә чыгу мөмкин булмаган эшкә әйләнеп бара, шунысы кызганыч. Бу җәһәттән интернет ярдәм итә, диләр инде. Аны бик белеп бетермим. Минем дә шактый җырларым бар, диләр анда. Үзем телефонны сөйләшү өчен генә файдаланам.

**:: Туксанынчы елларда сез «Болгарым», «Татар кешесе», «Алтын Урда» кебек тарихи җырлар башкардыгыз.**

– Үзгәртеп корулар заманы шундый җырлар таләп итә иде. Луиза Батыр-Болгари иҗат итә, мин башкарам. Андый кыю җырлардан азрак куркып калучылар да булды, мин башкардым инде. Болгар җирлегендә килгән кунакларны «Болгар» җыры каршы ала иде. Бик озак яңгыраттылар аны, аннан соң туктаттылар. Җырны файдаланмый башлауның сәбәпләрен белеп бетермим. Ләкин анда да кирәге булмагач, репертуарда тотуның кирәге юктыр дип, мин дә җырламый башладым. Гәрчә бик матур, бик мәгънәле җыр ул.

**:: Илһам Шакиров пластинкаларын тыңлап үстем, дидегез. Исән чакта аның белән күрешү насыйп булдымы?**

– Гомеренең ахырынача күрешеп тордык. Аның белән очрашулар – үзе бер гомер. Гадәттә Разил Вәлиев, Камал театрының ул чактагы директоры Шамил Закиров, галим Миркасыйм Госманов була иде. Мин гитара белән киләм. Алар гәпләшә, берзаман Илһам абый кулын күтәрә дә: «Әйдә, Рамил, «рвани»!» – дип әйтә. Мин берәр җыр әзерләп киләм инде. Бер юлы Әстерхан татарларының җырын башкардым. Бик ошады Илһам абыйга, сүзләрен сорап алды.

Мин Илһам Шакиров мәктәбен үттем. Әле дә истә: студент чакта аның бер концертында башымны аска иеп елаган идем. Ир башыңнан күз яшьләреңне күрсәтү дә оят, тыелып калып та булмый. Менә ничек тәэсир итә иде ул кеше күңелләренә!

Башта бит мин Илһам абыйга охшатып җырлый идем. Аның репертуарын ятлап, аның тавышын кабатлап. Без Фән Вәлиәхмәтов белән бергә укыдык. Ул Габдулла Рәхимкулов тавышы белән җырлый иде. Хәзер кара: нинди тавыш! Үз юлыбызга без әнә шулай килдек.

**:: Сез артист, диңгезче, шахтер булгансыз. Тормышның кайсы чорын иң матур чак дип искә аласыз?**

– Балачагымны. Авылымны, аның гүзәл табигатен, балык тоткан мәлләрне... Калган чорларны да сабак биргәне өчен рәхмәт белән искә алам. Иң кызыгы: кайсы чорда да җырдан аерылмаганмын икән. Шахтер булып эшләгәндә, ансамбль оештырдым. Мин киткәч, төркем дә таралды.

**:: Олыгайган көндә туган ягыгызга кайтып төпләнәсе килмиме?**

– Туган җирем – Башкортстан, туган илем – Татарстан. Туган авылыма ел саен кайтам, иң беренче зиратка кереп, әрвахлар рухына дога кылам, аннан төп нигезгә юнәләм, туганнарым белән күрешәм. Бераз торганнан соң, Казанны сагына башлыйм. Бирегә сагынып кайтам. Иҗатыма мөмкинлек биргән җир дә, гомер иткән җирем дә бит ул.

**:: Үземнең мәхәббәтемне таптым, дип әйтә аласызмы хәзер?**

– Әйтә алам.

**:: Сез – тулысынча ачылган артистмы?**

– Юк, билгеле. Шунысына сөенәм: ничек кенә булса да, үз юлымнан тайпылмадым. Заказ буенча бернәрсә дә эшләмәдем. Череп байый да алмадым, фәкыйрьлектә дә яшәмәдем. Яңа җырлар иҗат итәм. «Минем телем», «Җәйсыз дөнья», «Син мине сагынма» – әле генә табадан төшкән җырлар. Кыскасы, тормышым зарланырлык түгел. Шөкер итеп яшим.

**:: Эстрада хәлләренә нинди бәя бирәсез?**

– Мин һәрвакыт, җырның ертыгы юк, дип әйтәм. Җырларга кирәк. Безнең халык җырлап яши ул. Телевизорны ачсаң да күренә бит: тегендә – сәяси уеннар, монда – ызгыш. Татар каналын ачасың: эшлиләр дә җырлыйлар, эшлиләр дә җырлыйлар. Аллага шөкер!

**:: Мөмкинлек булса, тормышыгызда нәрсәне үзгәртер идегез?**

– Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем. Бернәрсә өчен дә үкенмим. Барысы өчен дә: һәр гамәл, һәр сүз өчен үзең җавап бирәсе. Әнә шуны онытырга ярамый.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

## ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

# УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

< Дәвамы. Башы 14, 21, 28 октябрь саннарында

Нәфисә ачык ишектән эчкә үтте дә туктап калды. Аны күргәч, умарта күче кебек гөжләп торган мәктәп шым булды. Кызчык, Камилнең барлыгын да онытып, әле бер кешегә, әле икенче кешегә талпынды. Кечерәкләр, куркып, олыраклар артына качты, олылары, нәумизләнеп, бер-берсенә карашты. Ул арада Илнур белән Илсур килеп җитте, алар тиз генә сеңелләрен күтәреп алдылар да өйләренә йөгерделәр.

Бу хәл Каракүлне тагын бер дулкынландырып алды. Авыл янә икегә бүленде.

– Балалар куркып калганнар, хәл итегез, югыйсә зурга җибәрәбез! Мөртәтләр! – дип янады ат биленнән төшмәс Зарифә. Аны яклаучылар: «Әйе, дөрес!» – дип мөһер сугып тордылар. Бу сүзләрдән соң Фатыйма урамга бөтенләй чыгып йөрмәс булды, Мостафа балтасын кысыбрак тотты.

– Фәрештә кебек бала, уйныйсы килә инде аның, дәвалап карарга кирәктер, берәр дәвасы бардыр, – диеште калганнар. «Гарип түгел, нидән дәваларга соң аны? Ул түгел, сез әпәләнәсез бит», – дип җавап бирде күз яшьләренә буылып Фатыйма.

– Авылдан кудыртам, сихерегез белән авызны яба алмассыз! – дип зәһәрләнде Зарифә. «Китсеннәр!» – дип утка утын өстәделәр аны хуплаучылар. Хәтта: «Иремне аздырасың!» – дип атна элек кенә Зарифә белән канга батып сугышкан Кәримә дә аңа иярде. Ул вакытта Зарифә ирле-хатынлы Тимергали белән Кәримәнең икесен бергә тотып кыйнады. Шул вакытта тегеләре, «этнең койрыгын кем киссә, шул яхшы» дигәндәй, Зарифәгә каршы килмәскә кирәген яхшы аңлап калдылар.

– Тәүбә, диген, Фатыйманың да, Мостафаның да кешеләргә бер начарлыгы да тигәне юк бит әле, ни сөйлисең? – дип яклады бүтәннәр.

Каракүлдәге һәрбер яңалыкны саескан урынына такылдап, очраган бер кеше белән пешеп җитмәгән ит кебек тәме беткәнче чәйнәргә өйрәнгән Миңнегали карт, Нәфисә тугач, бу турыда бертөрле дә фикер белдермичә, тешсез авызында тәрепкәсен генә әвәләп, дәшми генә йөргән иде. Авылдашларының шушы рәвешле бүленүен күреп, хафага төште. Кешене авылдан куу – ике башлы таяк ул: куылучыларга да, куучыларга да тап төшерә. Үзләре, китәбез, дигәндә дә, юл куймаска кирәк. Китеп, кая барсыннар? Бала – үзебезнеке! Шулай уйлады Миңнегали карт. Ике якны да канәгатьләндерә торган сүз табарга кирәк иде, һәм ул тапты да:

– Чү, сүзгә килмәгез. Мин – яугир кеше, мине әнә сугышта булганнар яхшы аңлар. Без сугышта яхшымы, начармы дип уйлап тормый идек. Туган ил хакына, туган җир хакына да утка керә идек. Утка кер, дисәләр, утка кердек, суга төш, дисәләр, суга төштек. Ә сез монда туган җирне бүлешеп ятасыз. Бүленми ул. Һәркайсыбыз өчен дә тигез. Вәт. Мин әйттем, – диде. «Шулай, шулай», – дип баш селкеде сугыш ветераннары. Аның каравы Нәфисәгә Камилнең әнисе Энҗебикә сөенде. Кызчыкны җитәкләп йөгергән көннән соң, улын алыштырып куйган кебек булды. Моңа кадәр: «Мәктәптә укымыйм, көтүче булам!» – дип йөргән малае, кинәт кенә бу уеннан кире кайтып: «Мин галим булачакмын, шулай кирәк», – диде дә көне-төне китапларына ябышып ята башлады.

– Фатыймакаем, сезнең кызны күргәч, Камилем «бишле»гә генә укый башлады бит. Галим булам, ди, Нәфисәне терелтәм, ди.

Энҗебикә сөенә. Фатыйма гына ни сөенергә, ни көенергә белми: Нәфисә бит – дүрт саны төгәл, саф зиһенле, камил бала! Кешеләр бит, аны күргәч, үзләре үзгәрә. «Барысы да яхшы, без бергә!» – ди ул Мостафасына, утларны сүндереп йокларга яткач, күзгә йокы эленмәгәндә. «Китап сүзе сөйләмә миңа, күз күрер, йокла!» – ди гадәттә ире.

Тыштан кыя кебек нык торса да, Мостафа бәләкәй кызының зур үсәчәген, аның дөньяга чыгасы, ишләре белән уйныйсы, гашыйк буласы, мәхәббәт утында янасы, кияүгә чыгасы, бәбиләр үстерәсе киләчәген яхшы аңлый иде. Бөтен кеше дә шулай яши: туа, үсә, гашыйк була, бәхетле булам дип тырыша-тырмаша, үзеннән соң эз калсын – нәсел дәвам итсен дип, балалар үстерә, картая һәм үлә. Шул ук вакытта Нәфисәкәйне кирәгеннән артык гүзәллеге, өстәвенә кешеләрне гипнозлаган кебек телсез калдыру сәләте белән яшәргә өйрәтергә дә кирәк. Уйлана торгач, Мостафа бу вазгыятьне үзенчә, һәрхәлдә, кулыннан килгәнчә хәл итте: ул бакча артларына Нәфисәгә дип тагын бер йорт салып бирергә булды. Бөтен гомерен шуңа багышласа багышлар, ләкин Нәфисәгә хан кызларыныкы кебек мәһабәт сарай төзер. Кем белә, тора-бара, бәлки, кызы гап-гади бер балага әйләнер, йә булмаса, галимнәр аны өйрәнеп, берәр дәвасын табарлар. Әнә бит Энҗебикә малае ничек кызыксынып китте. Үзенең уллары Илнур белән Илсур да берсе – Нәфисәне саклар өчен хәрби, икенчесе сеңлесенең үзенчәлеген ачыклар өчен галим-табиб булам, дип хыялланa. Икесе дә укуда алдырып киттеләр, гел яхшы билгеләренә генә укыйлар хәзер. Юк, ялгыз булмаячак аның кызы. Ялгыз булмаячак!.. Кем дә кем Нәфисәнең табышмагын чишсә, ул шуңа булачак.

Ә менә Камилгә чынлап торып гыйлем чире кагылды. Бер ел дигәндә, ул мәктәп китапханәсендәге китапларны укып чыкты. Икенче елны авылныкын. Ләкин ни хикмәт: ул китапларда Камилнең сорауларына җавап бирердәй белем юк иде. Тугызда укыганда, Камил төрле университетларга язды, ләкин алар Камилгә, төрле мәсьәләләр чишеп кара, дип әсбаплар гына җибәрделәр, теорияләр белән таныша тор, мәктәптән соң укуыңны дәвам иттерергә безгә килерсең, дигән җаваплар белән генә чикләнделәр. Шулай да Казанның медицина институтыннан бер профессор аңа гипноз серләрен өйрәнә торырга кушып, хат язды. Конвертка гипноз турында бернигә кулланма да салган иде.

Бу хатны алган көннән соң 14 яшьлек Камил яңа дөньяда яши башлады. Гипноз! Кулланмаларны йотып кына куйды үсмер һәм әнисе күзеннән ераккарак яшеренергә булды. Мәктәпне медальгә тәмамларга торган улының, галимлекне ташлап, «шарлатаннар шөгыле»нә күчүенә мәңгегә дә разый булмаячак иде Энҗебикә. Шуңа да гипнозны тәмам үзләштергәнче, Камил әнисенә берни дә сиздермәскә булды. Сизмәсен өчен, аның күзенә мөмкин кадәр сирәгрәк чалынырга кирәк иде. Камил үзенең лабораториясе итеп бакча артындагы юкәлек уртасында үсеп утырган йөзьяшәр имәнне сайлады. Буш вакыты булдымы, Камил шунда йөгерә. Озак итеп бер ноктага карап, йә булмаса озак итеп күзләрен йомып утыра. Гипнозларга өйрәнү өчен шулай кирәк, дип уйлый. Гипноз турында булган бөтен мәгълүматны тиз арада ятлап алганнан соң, аның тизрәк практикага күчәсе килә иде.

Беренче пациенты итеп ул әнисенең кадерләп кенә асраган җан иясен – йомшак йонлы, назлы, шул ук вакытта Камилгә карата кырыс холыклы Бохар мәчесен сайлады. Юкка түгел, мәче үзе еш кына теләсә кайсы бер почмактан аны гипнозлагандай усал карашы белән күзәтә иде. Камил өйдә вакытта аның бу карашыннан тәмам туеп, мәчене өйдән сөреп чыгарыр дәрәҗәгә җитә, әнисе яратканга гына түзеп тора. «Әйдә, Бохар, кадерле җан, синең чират! Нәфисә хакына! Фән хакына!» – диде ул, мәчене сизмәгәндә генә эләктереп алып. Әнисе, кичке савымга дип, фермага киткән иде.

Бохар мәчесе йонын кабартырга өлгерми дә калды, Камил аны кочагына алып, йомшак итеп сыйпый башлады. Мәче шикләнсә дә, каршы килмәде. Шуннан яшь гипнозчы хайванны аркасына салып, тәпиләрен гәүдәсенә терәде. Тегесе күзләрен йомып, мырларга кереште. Алга таба Камил аның тәпиләрен әкрен генә бөтен буена тарткалады һәм... шул мизгелдә Бохар мәчесе мәрткә киткәндәй тынып калды. Бераздан Камил аны теләсә нинди кыяфәтләргә кертеп әвәләп карады, мәче балавыз кебек иде. Үсмер шатлыгыннан нишләргә белмәде. Шунысы кызганыч: бүлешер кешесе юк. Дөресрәге, бу аның сере иде. Әле Бохар кунагын уятасы да бар. Анысын нинди техника белән эшләргә икәнен белми иде әле ул. Әнисе кайтканчы ничек тә мәчене үз хәленә кайтарырга кирәк, югыйсә эләгәчәк! Энҗебикә – бер карашы белән генә дә тәрбияли белә торган хатын. Берьюлы әти дә, әни дә ул бердәнбер улы өчен.

Бәхет бер килсә, ишелеп төшә бит ул: уятасы да булмады, мичтә янган утынның шарт итеп шартлавы булды, мәче сикереп тә торды. Камил, янында шатлыгын уртаклашырдай бердәнбер җан иясе булгангамы, әллә мәчене җиңә алуына сөенепме, аңа аштан тәмле калҗа алып бирде. Шуннан соң Бохар егет артыннан ияреп йөрер булды. Имән төбенә дә ияреп бара хәтта. Берсендә ул Камилгә тычкан тотып алып килеп бирде. Кыр тычканы тере, алай гына да түгел, Бохар аны имгәтмәгән дә иде бугай. Алып килде дә Камилнең учына салды. Һәм карап тора башлады, карашы белән: «Әйдә, тәҗрибәләреңне кабатла!» – диюе булды, ахрысы. Тычканнан да балавыз ясады Камил. Һәм мәчегә бирде. Бохар аны алгы тәпие белән тегеләй әйләндерде, болай тәгәрәтте дә, «Молодец, булган бу!» дигәндәй хуплап, Камилгә карады. Озакламый алар тавык кетәклегенә керделәр. Берьюлы әтәче белән биш тавыкны тезеп салды Камил. Шулай бәтиләр янына кереп китте. Камил аның артыннан. Ул арада фермадан кайтып, кетәклеккә йомырка карарга кергән Энҗебикә тезелешеп яткан тавыкларны күреп, чырыйлап кычкырып җибәрде. Шуны гына көткән кебек тавыклар да сикереп торды. Өстәвенә, әтәче йоклап торгач, таң дип белеп, бертуктаусыз кычкырырга тотынды. Шулай итеп, ул көнне бәтиләргә чират тими калды.

Дәвамы бар >

Шигърият

Алмаз МАНСУРОВ

## ХУШЛАШУ

*Киттең, октябрь,*
*Үпкәләп...*
*Соңгы көнең*
*Бик күңелсез!*
*Тырышсак та,*
*Хисләр белән*
*Сердәшичәләр*
*Түгел бит без!*
*Җан дуслар да*
*Түгел бит без!*

*Син кызганмый*
*Җылы көннәреңне*
*Учларыма салдың –*
*Шунда хатаң!*
*Рәхмәтсез мин,*
*һәм рәхимсез бугай...*
*Бу гамәлне*
*Бер дә*
*Аңлый алмам.*

*Зинһар,*
*Кичерә күр, бу дөньяда*
*Минем кебек*
*Тиле гашыйк азмы?!*
*Ни кылсаң да,*
*Ниләр эшләсәң дә,*
*Мин барыбер*
*Сөям*
*Салкын язны.*

## ДУСКА

*Сагынганбыз...*
*Чын ирләрчә*
*Күрештек без,*
*Кулны бәреп кулга.*
*Хисләр йомарланды –*
*Күрсәтмәдек,*
*Тыйнак идек никтер*
*Мин дә, ул да...*

*Үзгәрәбез,*
*Егет юләрлеге*
*Иреннәрдә калды,*
*Тик елмаю булып.*
*Тормыш йөге,*
*Гаилә...*
*Муеннарны*
*Камыт тора хәзер*
*Ныклап буып.*

*Үзгәрсәк тә,*
*Үзгәрмичә калган*
*Калебтәге кул сузымы ара.*
*Кулны кысышканда,*
*Дуслык хисе*
*Мәңгелеккә*
*Йөрәкләрдә кала.*

## КИТЕП БАРАМ

*Сүзләр артык.*
*Моңсу бу халәттән*
*Чыгу юлы, ахры,*
*Юк, булмас.*
*Җылы караш...*
*Тырышып та торма!*
*Дәваламас хәтта*
*Сөю, наз!*

*Китеп барам*
*Үзем белгән юлдан!*
*Мизгелләрнең тәме җуела.*
*Үз максатым, үз хыялым белән*
*Мин ялгызым калам бу юлда.*

*Язмышларны җимерүе җиңел,*
*Салкын җилләр керсә арага.*
*Калебләр дә бер җөйләнер, бәлки,*
*Җылы өреп булса ярага.*

# БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның
беренче яртыеллыгына
**«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»**
газетасына языл

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

**П2435**
жомга саны
**512 сум 70 тиен**

**П2409**
атнага дүрт тапкыр чыга
**1143 сум 96 тиен**

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама


## Әз-мәз мәзәк

*– Безнең директор әйтмешли, бер ишек ябылса, икенчесе ачылыр.*
*– Гафу итегез, ә сезнең автосалонда башка машина юкмы?*

* * *

*– Лилия, егетең килгәч, син гел күзлегеңне саласың. Ник алай?*
*– Мин күзлексез матуррак күренәм. Егетем дә миңа матуррак күренә.*

* * *

*Туйдан соң, хатын минем фамилиямне алды. Хәзер мин Мансур, бары тик Мансур.*

* * *

*Дүшәмбедән яңа тормыш башлаучы кеше, гадәттә, аны сишәмбе тәмамлый.*

* * *

*– Синең әти-әниең кайда танышкан?*
*– Авыл клубында, дискотекада.*
*– Ой, шундый романтично!*
*– Романтично дип... Әни никтер биемәгән, ә әти урамнан керен, бердәнбер биеми утырган кызны трактор этәргә алып чыгып киткән.*

* * *

*Рекламада «кулай бәядән» дигән сүз ишетсәгез, белегез: сүз сатучыга кулай бәя турында бара.*

## Файдалы киңәшләр

✓ Хатын-кызның яшен сорамыйлар. Нинди җанвар елында туганын сорагыз. Көнчыгыш гороскобының бер әйләнеше – 12 ел, шуннан чамаларга була.

* * *

✓ Күп кешене берьюлы фотога төшергәндә күзләре йомылмасын өчен бер хәйлә бар. Башта барысы да күзләрен йома. Фотограф «бер, ике, өч» дип кычкыргач, ачалар. Шул мизгелдә фотоаппараттан чыпчык очып чыга.

* * *

✓ Телефоныгыз зарядканы тизрәк җыйсын дисәгез, аны «самолет» режимына куегыз.

* * *

✓ Өйдә утны бетерсәләр, экраны кабынган смартфон өстенә бер шешә су куярга була. Лампа урынына менә дигән!

* * *

✓ Башка күршеләрдә дә утны бетергәннәр микән дисәгез, моны тикшереп карарга була. Телефоныгыз белән якын-тирәдәге Wi-Fi челтәрләрен эзләп карагыз. Берсе дә табылмаса, димәк, бөтен подъездда дөм!

## Беләсең килсә...

**1 Бу елның февралендә Чиләбе өлкәсенә зур метеорит төшә:**
а) 2013;
б) 2015;
в) 2016.

**2 Норма Джин Мортенсон исемле хатын нинди тәхәллүс белән дөньяга танылды?**
а) Софи Лорен;
б) Мэрилин Монро;
в) Мадонна.

**3 Әлеге җырчы Татарстанның халык артисты Усман Әлмиев җитәкчелегендә Сембер өлкәсендә татар артистлары бригадасында берничә ел эшләгән.**
а) Зөһрә Шәрифуллина;
б) Әлфия Авзалова;
в) Флюра Сөләйманова.

**4 Бу шәһәрнең халык саны 20 млн кешедән артык:**
а) Каһирә;
б) Мәскәү;
в) Истанбул.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. а).

**Сканворд җаваплары**

**Горизонталь:** чардуган, сәлкеш, Дилбәр, мие, шагыйрь, сейф, әр, гив, ни, кайнана, Ялла, лира, Намус, Ту, ышкы, Роксана, мәл, Ырга, рок, ля, ятимә, Иштуган, имү.

**Вертикаль:** Чирмешән, Илнар, Еники, ария, Иа, он, Ярмәк, ышкылау, Стас, Рәйхан, ун, ас, Амур, Ян, Нәсим, га, оят, Лисин, ымлык, Скабеева, Ми, Әгъләм, Шәрәфиев, арыш.

**Газетаның киләсе саны 8 ноябрьдә чыга.**

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде


**Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Индекс П2435**
**Тираж – 15337 данә**

**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 363

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+